• ВАКЫЙГА •

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА ЯЗЫЛ

*2019 елның 1 яртысына язылу бәясе 132 сум. Язылу индексы П4333*

• МИНБӘР •

РӘГАИБ КИЧӘСЕ ЯКЫНЛАША

*4 бит*

• ВӘГАЗЬ •

ИСЛАМДА ИР-АТ ВАЗИФАЛАРЫ

*6 бит*

• СОРАУ – ҖАВАП •

ХӘЛӘЛ БУЛМАГАН РИЗЫКНЫ НИШЛӘТЕРГӘ?

*7 бит*

*№ 2 (283)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *раҗәб – шәгъбан 1440*

*февраль, 2019*

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# «Нигезләмәгә таяну күп проблемаларны хәл итәчәк»




*Дәвамы 8 нче биттә*

15 февраль көнне фаҗигале рәвештә, автоһәлакәткә юлыгып, Мөслим районы имам-мөхтәсибе **Венер (Габделкәрим) хәзрәт Моратов** арабыздан китте. Хәзрәткә 36 яшь иде, аның тормыш иптәше һәм алты баласы калды. Мөхтәсибәт җитәкчесе вазифаларын ул 2017 елның июнь аеннан бирле уңышлы башкарып килде.

Дин кардәшләребезнең күпсанлы мөрәҗәгатьләрен искә алып, нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан шулай ук аерым хисап счеты ачылды. Теләгән һәркем түбәндәге реквизитлар буенча шулай ук ярдәм җибәрә ала:

**Юридик затлар өчен:**

Благотворительный Фонд «Закят»

ИНН/КПП 1655068682/165501001

ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012

р/с № 40703810662190000765

(Советское отделение № 6669/015 СБ РФ г. Казани)

ОСБ БАНК ТАТАРСТАН № 8610 г.Казани

к/с: 30101810600000000603 БИК: 049205603

Юридический адрес: 420111, г. Казань, ул. Лобачевского, д. 6

**Физик затлар өчен:**

Карта Сбербанк 5336 6900 0273 6009 на имя Марданова Булата Раифовича.

**Моратов Венер Мөнирович гаиләсе өчен дип күрсәтергә (Назначение платежа: для семьи Муратова Венера Мунировича).**

# Болгарда IX Бөтенроссия Коръән укучылар һәм хафизлар бәйгесе узачак



21-22 февральдә IX Казан Бөтенроссия Изге Коръән укучылар һәм хафизлар бәйгесе узачак. Быел ул борынгы Болгар шәһәрендә үткәрелә.

Бәйгедә Россиянең 14 төбәгеннән: Татарстан, Башкортстан, Чечен, Дагъстан, Ингушетия, Кырым республикаларыннан, Ставрополь һәм Пермь крайларыннан, Мәскәү, Чиләбе, Иваново, Сарытау, Тула һәм Свердловск өлкәләреннән барлыгы 30га якын кеше катнашыр, дип көтелә. Катнашучыларның иң кечесенә 11 яшь, иң өлкәненә – 34.

Чараны Ислам Лигасының Бөтендөнья Коръән-хафизлар һәм Сөннәт эшләре оешмасы, Болгар ислам академиясе, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Коръән нуры» хәйрия фонды оештыра.

Бәйге ике номинация буенча уздырыла: «Изге Коръәнне дөрес итеп уку» һәм «Изге Коръәнне тулысынча яттан белү». Анда Россия Федерациясе гражданнары булган ир-егетләр катнаша ала. Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр һәм акчалата призлар тапшыру күздә тотыла. Моннан тыш, һәр катнашучыга истәлекле бүләкләр каралган.

Игътибар! Оештыручылар теләге булган һәркемне Коръән-хафизлар бәйгесен күрергә чакыра. Бушлай хәрәкәт итү чарасы – трансфер булдырылачак. Мөрәҗәгать итү өчен телефон: +7 (987) 296-48-45 (Илдар хәзрәт).

# Татарстан мөфтие Кыргызстаннан рәсми делегация белән очрашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 7 нче көнендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин дәрәҗәле кунакларны – Кыргызстан Республикасыннан эш сәфәре белән Казанга килгән рәсми делегацияне каршы алды. Делегация составына Кыргызстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең Беренче урынбасары Алмаз Кененбаев, Кыргызстан Республикасының дин эшләре буенча Дәүләт комиссиясе директоры Заирбек Эргешов, Кыргызстан Республикасының Россиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле Илчесе Аликбек Джекшенкулов һәм башкалар керде. Делегацияне «Милли Шура» рәисе Васил Шәйхразиев озатып йөрде. Кыргыз кунаклары сәфәренең төп максаты – Татарстанда дин өлкәсендәге вәзгыятьне өйрәнү, шулай ук Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең күпкырлы эшчәнлеге һәм Болгар ислам академиясе белән танышу. Аларны Татарстанда ислам үсешен гамәли һәм юридик көйләүче система: мәчетләрне теркәү һәм имамнарны аттестацияләүдән алып дүрт баскычлы мәгариф үсеше һәм экстремизмга каршы көрәш кызыксындырды.

Түгәрәк өстәл артында узган әңгәмәдә Татарстан мөселманнары башлыгы кунакларны сәламләде һәм аларны ислам үсеше өлкәсендәге хәзерге вәзгыять белән таныштырды. Мөфти хәзрәт кунакларга бүгенге көндә республикада 1500дән артык мәчет, 48 мөхтәсибәт һәм Россиядә иң нәтиҗәлеләрдән булган, 9 казыяттән торган казыятләр системасы турында сөйләде. Алга таба ул мөфтиятнең традицион Ислам кыйммәтләрен пропагандалауга юнәлтелгән эшчәнлегенә тукталды, бу эшчәнлек дини экстремизмны профилактикалау буенча иң мөһим эшләрдән санала: Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте «Хозур» нәшрият йорты медиапроектлары: «Хозур ТВ» мөселман телеканалы, «Азан» радиосы, «Ислам тудей» порталы, шулай ук татар һәм рус телләрендә басма массакүләм мәгълүмат чаралары һәм социаль челтәрләрдә актив аңлату эшләре – ислам турында уңай иҗтимагый фикер формалаштыру, халык арасында дини мәдәнияткә һәм татар рухи мирасына кызыксыну уяту максатыннан алып барыла.

Камил хәзрәт билгеләп узганча, 2018 елда Татарстанның ислам белем бирү йортларының беренче курсына 1158 абитуриент кабул ителгән һәм 407 студент укуын уңышлы тәмамлап, дини белем турында диплом алган. «Мәгариф системасын үстерү – экстремизмга каршы тору мәсьәләсендә иң мөһим өлкәләрнең берсе булып тора, – диде ул. – Бирелә Татарстан уку йортларында без Россия җәмгыяте һәм өммәтенең күпконфессияле һәм милли үзенчәлекләрен, традицияләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып әзерлибез».

Мөфти Болгар ислам академиясе, аның мөгаллимнәр һәм студентлар составы турында тәфсилләп сөйләде. Кунаклар, үз чиратында, шундый ук проектны – ислам академиясен – Кыргызстанда гамәлгә ашыру буенча планнары белән уртаклашты һәм, мөфтиятнең күпкырлы эшчәнлеге белән тәэсирләнеп, Татарстан мөселманнары башлыгын үз илләренә җавап сәфәр белән килергә чакырдылар.

Тулаем алганда, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең халыкара эшчәнлеге Татарстан Республикасының һәм мөфтиятнең абруен күтәрү, шулай ук ислам үсеше өлкәсендә халыкара аренадагы урынны ныгыту, дөньякүләм мөселман киңлеге һәм мәгариф берләшмәләре белән ике яклы бәйләнешта торуны арттыру максатыннан тормышка ашырыла. Әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте чит ил оешмалары белән элемтәләрне киңәйтү, яңа партнерларны нәтиҗәле юл белән эзләү һәм яңаларын җәлеп итү, мәгариф программасы, Коръәнне өйрәнү, социаль хезмәт күрсәтү спектрын арттыру нәтиҗәсендә сизелерлек уңышларга иреште. Әлеге бурычларны тормышка ашыру өчен, 2018 елда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин эш сәфәре белән 9 тапкыр чит илләргә чыкты, моннан тыш Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясе дә шәһәрнең мактаулы кунаклары белән очрашу урынына әверелде. Нәзарәттә мөфти чит ил вәкилләре – мөселман галимнәре һәм фән эшлеклеләре, дәүләт һәм иҗтимагый оешма җитәкчеләре, журналистлар һ.б. белән рәсми очрашулар үткәрде. Чит илләрдән килгән кунакларга Камил хәзрәт татарларда ислам дине тарихы һәм үсеше, мөфтиятнең күпкырлы эшчәнлеге турында сөйләде, шулай ук алар белән ислам диненең традицион кыйммәтләрен ныгыту өлкәсендәге тәҗрибәсе белән бүлеште. Кунакларда татар рухи мирасының байлыгы хакындагы мәгълүмат, татар дини мирасының ислам дөньясындагы урыны, Россиядә ислам үсеше, Татарстанда ислам мәгарифе өлкәсендәге казанышлар, экстримизмга көрәш һәм дәгъват эшчәнлеге шулай ук зур кызыксыну уятты. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең халыкара мөнәсәбәтләр үсеше өлкәсендә иң зур казанышы булып, БМОның Икътисад һәм социаль советы (ЭКОСОС) каршында консультатив статус бирелүе тора.

# Джиу-джитсу буенча ярышларда хаҗ һәм гомрәгә юлламалар уйнатылачак




Татар галиме һәм дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланган джиу-джитсу буенча III Бөтенроссия ярышларына әзерлек дәвам итә. Татарстан Диния нәзарәтендә аны оештыру буенча чираттагы киңәшмәдә ярышларның төп бүләге – хаҗга юллама янына тагын бер олы приз өстәлде. Җиңүчеләр арасында жирәбә тартып хаҗга юллама иясе билгеләнгәч, шундый ук ысул белән кече хаҗ – гомрәгә дә юллама уйнатылачак. Оештыру комитетының әлеге карары ярышларда катнашучыларның саны күп булу һәм спортчыларга җиңүгә өстәмә этәргеч бирү максаты белән бәйле. Дин кардәшләребез өчен мондый мөмкинлекне Татарстан мөфтияте һәм республиканың рәсми хаҗ операторы «ДУМ РТ Хадж» тудыра. Юлламалар ир-ат спортчылар арасында уйнатылачак. Ярышлар 23 февраль көнне Казанның «Ак барс» көрәш сараенда ачылачак. Алар ир-атлар һәм хатын-кызлар (2000 ел һәм 2000 елга кадәр туучылар) арасында оештырылачак.

Турнир Россиянең җыелма спорт командаларына кандидатлар исемлеген туплау һәм аларны халыкара спорт ярышларында Россия данын якларга әзерләү максатыннан уздырыла. Шунысы куанычлы, Россия дөньяда джиу-джитсу үсешенең дәрәҗәсе буенча лидерлар рәтендә. Ярышларда Россиянең күчле спортчылары катнаша – алар джиу-джитсу буенча беренче разрядтан да ким булмаган квалификациягә ия булырга тиеш. Спортчылар 12 үлчәү категориясендә ярышачак: ир-атлар арасында – 56 кг, 62 кг, 69 кг, 77 кг, 85 кг, 94 кг һәм 94 килограммнан югарырак, хатын-кызлар арасында – 49 кг, 55 кг, 62 кг, 70 кг, 70 килограммнан югарырак.

Актив һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте яшьләр сәясәтенең һәм дәгъват эшчәнлегенең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Спорт чаралары берләшү, татулыкны ныгытуның һәм яшь мөселманнар мохитендә, шулай ук традицион конфессия вәкилләре арасында дуслыкны һәм аңлашуны ныгытуның мөһим бер чарасы булып тора.

# «Зәкят» фонды «Хиҗаб бәйрәме» оештырды



ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды, Халыкара хиҗаб көненә багышлап, үзенчәлекле балалар һәм аларның әниләре өчен бәйрәм оештырды. Чарада барлыгы 100дән артык кеше катнашты.

Бәйрәм Изге Коръән аятьләре укудан башланды. Аннары киемдә мөселман традицияләренең фазыйләтләре турында вәгазь укылды. «Зәкят» хәйрия фонды генераль директоры Булат Мәрданов бәйрәмне оештыруга өлеш керткән иганәчеләргә, волонтерларга рәхмәт белдерде.

Чакырылган оештыручылар әниләр өчен мехенди һәм яулык бәйләү буенча мастер-класслар үткәрде. Бу вакытта балалар волонтерлар белән бергә ике кызыклы химик тәҗрибә ясады. Моннан тыш, сабыйларны йоннан картина ясарга өйрәттеләр.

– Мин, үзенчәлекле бала әнисе буларак, мондый очрашуларга бик шатмын, – дип кичерешләре белән уртаклашты Люция Емекова. – Биредә без белгечләрдән генә түгел, үзләренең үрнәкләре белән өметсезлеккә бирелмәскә ярдәм итүче башка әти-әниләрдән дә уңай энергия, көч алабыз. Психологлар, әти-әниләр катнашында уза торган башка очрашуларга да йөрибез. Әмма бу төр зур бәйрәмнәрне «Зәкят» хәйрия фонды гына оештыра, бик зур рәхмәт аларга.

Очрашу ахырында балаларны «Зәкят» фонды тарафыннан әзерләнгән бүләкләр һәм чәй өстәле көтте.


Фондның иң мөһим башлангычларыннан берсе – авыру балаларны дәвалауга матди ярдәм күрсәтү буенча махсус программа. Әлеге программа 2016 елдан бирле эшләп килә.

Авыру балаларга ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән тагын бер әһәмиятле проект булып «Үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен үзәк» проекты тора. Ул Россия Президентының грантлар җәмгыятен үстерүгә юнәлтелгән грантын файдаланып тормышка ашырыла.

Татарстан өчен уникаль саналган әлеге проектның 2017 елның ноябрендә башланган беренче сезоны кысаларында 130 гаилә өчен 500ләп дәрес үткәрелде. Яңа сезонда проект «Хәят» исеме астында эшли башлады һәм үзенә йөрүчеләр санын 250 кешегә кадәр арттырды. Үзенчәлекле балалар һәм аларның әти-әниләре өчен Үзәккә йөрү бушлай.

■ dumrt.ru

# Нәзарәттә Дагъстан кунагы



Җөмәдәл-әүвәл аеның 29 нчы көнендә Диния нәзарәтендә Дагъстан мөфтие ярдәмчесе Мөхәммәд Магомедов булды.

Мөхтәрәм кунак Татарстан мөфтиенең хәнәфи мәзһәбе галиме, Коръәнхафиз буларак, гакыйдә, фикһ, Коръән гыйлеме, тәфсирләр өлкәсенә кагылышлы фикерләре, Диния нәзарәте нәшер иткән Коръән басмасы белән кызыксынды.

Камил хәзрәт үз чиратында дини мәгърифәтчелек юнәлешендә алып барылган күпкырлы эшчәнлек: татар һәм рус телендә Коръән тәфсире әзерләү, «Хозур ТВ» беренче мөселман телевидениесе тапшырулары белән Россия төбәкләренә чыгу хакында сөйләде. Бүгенге көндә «Хозур ТВ» тапшыруларын кабельле телевидение аша Түбән Новгород, Оренбург өлкәсе һәм Башкортстан мөселманнары карый ала. Мөхтәрәм кунакка мөфти хәзрәт «Хозур» нәшриятында бастырган китапларны бүләк итте.

# Рәгаиб кичәсе якынлаша



## Һәр нәрсәнең пары бар

Аллаһы Тәгалә барча мәхлукатны парлы итеп яратты. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

**«Дәхи, сезне парлы (ирле-хатынлы) итеп халык кылдык».**

«Нәбә / Хәбәр», 78:8

Кояш белән Ай, җир белән күк, ут белән су, җәннәт белән җәһәннәм – барысы да парлы. Кошлар, хайваннар дөньясында да ир һәм хатын җенесләре бар. Атабыз Адәм галәйһиссәламне яратканнан соң, Аллаһы Тәгалә аның кабыргасыннан Хәва радыяллаһу ганһәне ярата. Шул вакыттан бирле ир-ат белән хатын-кыз пар булып, гаилә булып яши. Ислам дине гаиләне нык саклый. Гаилә ул – калкан. Ә гаиләнең башлангычы исә – никах. Шәригатебез ир-ат белән хатын-кызның никахсыз мөнәсәбәтләрен катгый тыя:

**«Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш вә бик яман юлдыр».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

## Рәгаиб – нинди кичә ул?

Никах – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте. Раҗәб аеның беренче атнакичәнә туры килә торган Рәгаиб кичәсе безгә шул хакта искә төшерә дә. Раҗәб ае быел 7 март көнне ахшамнан соң башлана.

«Рәгаиб» дигән сүз гарәп телендәге «рәгабә» фигыленнән алынган, ягъни «нәрсәнедер теләү, шул теләгәнеңә ирешү өчен тырышу» мәгънәсен бирә. Шәргый яктан караганда, бу расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе белән әнисе никахлашкан көн. Ягъни бу – Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә белән әтисе Габдуллага никах укылган һәм алар, ир белән хатын булып, Әминә безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә авырга узган вакыт.

Күп кеше шушы кичәдә нишләргә дигән сорау бирә. Догада булыйк, намаз укыйк, садака бирик. Гомумән, бер көндә дә гыйбадәтләребезне киметмик. Аеруча шушындый мөбарәк кичәләрдә нәфел гыйбадәтләребезне арттырыйк. Аллаһы Тәгалә каршында иң сөекле гыйбадәт – кыска, әмма дәвамлы булганы.

Шуны да искә алыйк – Рәгаиб кичәсе раҗәб аеның беренче атнакичәнә туры килә, ягъни пәнҗешәмбедән җомгага каршы кич була. Быел ул милади буенча, ин шә Аллаһ, 7 нче март кичәсе булачак. 8 нче март – дәүләтебездә Халыкара хатын-кызлар көне булып билгеләнелә. Илебездә бу көн рәсми рәвештә ял булып санала. Димәк, пәнҗешәмбе иртәсеннән уразага кереп була. Нәфел, өстәмә ураза өчен иң хәерле көннәр булып дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе санала. Кич, кояш баегач, фарыз намазларыннан соң нәфел намазларын да укырга була. Төнге тәһәҗҗуд намазлары аеруча саваплы санала. Икенче көнне госелләнеп, җомга намазына барасыз. Ялны файдалы, саваплы үткәрү өчен бу бик яхшы форсат.

## Балаларыбызны никахка әзерлибезме?

Рәгаиб кичәсеннән без нинди дәрес-гыйбрәт алырга тиеш? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы Габдулла – бай нәселдән, затлы, белемле егет булган. Әнисе Әминә дә – күркәм, матур нәселдән. Алар Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән никахлашканнар. Без, ир-атлар, – гаилә башлыклары, хатын-кызлар – йорт учагын саклаучылек әти-әниләр килә дә: «Минә бит, хәзрәт, егет тә яхшы, әти-әнисе дә бик тәрбияле, ләкин безнең милләттән, безнең диннән түгел, нишлик?» – дип зар елый. Хөрмәтле әти-әниләр! Балаларыбызны никахка әзерләү – безнең бурыч! Телибезме, теләмибезме – без моны үтәргә тиеш. «Хәзрәт, нишлик инде, башка милләттән, башка диннән; никахсыз яшиләр, никахсыз балага узганнар», – дип елап киләбез

> Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм раҗәб аенда уразаларын күбәйтә иде. Хәдис-шәрифләрендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб – ул утырту ае, шәгъбан – ул су сибү ае. Аннан соң килә торган Рамазан – уңышны җыю ае. Раҗәб ае җитте икән – димәк, без Рамазан-шәриф аена якынлашабыз. Димәк, Рамазанга инде ныгытып әзерләнү кирәк», – дип әйткән.

лар, балаларыбызны никахка әзерлибезме? Үзебезгә иң элек шушы сорауны бирик әле. Әллә кызыбыз йә улыбыз укырга дип шәһәргә китеп, күпмедер вакыттан кайтып төшә дә: «Әтием, әнием, минә бу минем булачак ирем/хатыным», – дип, кисәк кенә хәбәр бирәме? Шунда гына, аһ-ваһ килеп, мулла эзләргә, никахка әзерләнергә тотынабызмы? Аллаһы сакласын, никахка кадәр үк балага узган очраклар да бар бит. Никахларга барабыз, ә килен инде бала көтә, шуны мулладан ничек яшерик икән дип тырышалар. Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын.

Монысы беренче мәсьәлә. «Әйе, без балаларыбызны никахка әзерлибез», – дип җавап бирсәк, сезгә икенче сорауны бирәм: без аларны кайсы вакыттан алып никахка әзерлибез? Мәктәптәнме? Әллә шул кызыбыз университет-институтка киткән чакта гынамы? Нинди сүзләр белән әзерлибез? Үзебезнең милләттән булсын дибезме? Мөселман егете булсын дибезме?

Безгә, хәзрәтләргә, көн саен диярикән – димәк, без, әти-әниләр буларак, үз вазифабызны үтәмәгәнбез. Рәгаиб кичәсе шуның белән кыйммәтле: Габдулла белән Әминәне ничек итеп тәрбияләделәр, ничек итеп никахка әзерләделәр, ничек итеп никахландырдылар – бу безнең өчен үрнәк, искә төшерү. Без дә шулай итәргә тиеш: ул үстерәбез икән – аны ир-ат итеп тәрбиялик, якынтирәбездә, дусларыбыз-танышларыбызда кайсыларында кыз үстерәләр – шуларны өйрәник. Нәселе, җиде буыннары нинди – тикшерик. Нәсел шәҗәрәсе дип күпме авыз корытабыз – ул бит матур агач кына түгел. Ул – нәселнең тарихы. Кемнәр булган, нинди булган – өйрәник, белик. Кыз үстерәбез икән – әдәпле, әхлаклы, тәртипле, иманлы, чын мөслимә булырлык итеп тәрбиялик. Балаларыбызны кечкенә чакларыннан ук дөрес итеп үстерик.

## Исемең матур, кемнәр куйган?

Никахтан соң күп вакыт та үтми – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе сәфәргә чыккач, вафат була. Бала дөньяга ятим булып туа. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бабасы, Габдулланың әтисе киленне беркая да куып җибәрми: «Баланы табасың, сине карыйбыз, баланы тәрбиялибез», – дип әйтә. Ул вакытта гарәп кабиләләрендә гадәтләр кырыс булган. Ләкин бу гаиләдә берәү дә киленне куып чыгармый. Шушы бабасы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тугач, аны, Кәгъбәтуллаһ янына алып барып, аңа Мөхәммәд дип исем куша. Рәгаиб кичәсенең безгә искәртә торган тагын бер мәсьәләсе – без балабызга хәерле, матур, мәгънәле исем сайларга тиеш. Балаларыбызга да шуны өйрәтергә тиешбез.

Яңа туган сабыйларны мәчетләргә алып килиләр: нинди генә исемнәр юк! Моннан тәүбә итү кирәк. Шушы Рәгаиб кичәсендә Аллаһы Тәгаләгә ялварыйк, оныкларыбыз, аларның балалары һәм нәселебезнең киләсе буын дәвамчылары хәерле исемнәр йөртсен, әдәпле-әхлаклы, тәрбияле булсын, дип сорыйк. Раббыбыз әле никахлашмаган яшьләргә хәерле ирләр, хатыннар бирсен.

* * *

Рәгаиб кичәсе безгә гаилә тәртипләрен күрсәтә торган кичә. Габдулла белән Әминәнең никахлашуы, шушы никахтан Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууы, аның хатыннары белән ни рәвешле никахлашуы, гаиләдә мөгамәлә кору рәвеше – болар барысы да мөселманнар өчен үрнәк булып тора. Без алардан өйрәнеп, аны үз балаларыбызга да җиткерергә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә имин тормыш, бәрәкәтле гомер бирсә иде. Әмин!

**Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы**

# Өйләндерүдә ата вә ана вазифасы



Иргә тапшыру вакыты килеп җиткәч, кыз баланы, никадәр генә малсыз вә җиһазсыз булса да, динле, гүзәл тәрбия алган кешегә бирү өчен тырышу – ата вә ана вазифасыдыр. Аллаһы Тәгаләдән куркучы вә халыклардан оялучы зат, хатынын сөйсә, хөрмәт белән тотар. Әгәр дә, Аллаһы сакласын, мәхәббәте булмаса, җәфага салмас.

Малына яки дәрәҗәсенә кызыгып, бозык инанулы, диндә игътибарсыз кешеләргә кыз бирү ярамый. Дөнья малы никадәр күп булса булсын, вә дөнья дәрәҗәсе никадәр биек саналса саналсын, Ахирәт гамәленә күчереп исәпләгәндә, юк хөкемендәдер.

Газиз Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләренең иярченнәре (табигыйннәре) арасында беренче остаз булган Әбү Мөхәммәд Сәгыйд бине Әл-Мөсәййиб хәзрәтләре, хөрмәтле бөек ханымнарны ул вакытның хәлифәсе булган Габделмәлик бине Мәрван үзенең тәхет варисы – углы Вәлид – өчен сораганда, кире кагып, сәхабәләр төркемендә иң фәкыйрь булган, бер яки ике, яки өч дирһәм мәһәр бәрабәренә өйләнгән кешегә (кызын) биргән иде.

Балаларны өйләндергәндә, ата вә ана өчен балаларны җәберләү рөхсәт ителмәгән кебек, тәмам үз ихтыярларына салып, бер читтән күзәтүче булып тору да ярамый.

Тәмам үз ихтыярларына бирелсә, яшьлек исереклеге вә милек һәм көчле солтан булганлыгы сәбәпле, ихтимал ки, ялгышырлар, вә ялгышуларын да белми калырлар. Вә моның нәтиҗәсе буларак, олуг үкенечләргә очрарлар.

Хәл болай булганда, ата вә ана үзләренең камил солтан булуларын, балаларын өйләндерүдә үз ихтыярларына куюны угылларына вә кызларына сөйләү, алар ниятләгән нәрсәдә булган хәвеф-куркуларын аңлатып бирү тиештер.

Ирексез сурәттә булган никахта күңелләр бер-беренә охшамаганлыктан, тормышлары зәһәрле вә иң дөресе – җәһәннәм газабы дәрәҗәсендә авыр булу мөмкиндер. Балаларның бәхетле булуын теләгәндә, көчләп никахлау ярамас.

Ирексезләү белән яки ирексезләүгә бик якын булган никахларның еш таралган сәбәбе – ирләрнең карт вә яки бай булып, кызларын бай хатыны итү белән бәхетле яшәтү теләге булыр. Ләкин бәхет дип аталган нәрсә һичвакытта мал белән сатып алынмас.

Шуның өчен, яшь кызларны яшьләренә туры килмәгән картларга, тәрбияле кызларны тәрбиясез байларга бирү – бәхет өмет ителәчәк өйләнешү булмыйча, фәкать мал бәрабәренә барлыкны вә бәхетне сатудыр.

Гакыл вә шәригать җәһәтенчә теләнгән никах – ата вә ана, вә өйләнүче балаларның ризалыклары вә шатлыклары белән булган никахтыр.

Әгәр дә балалар, үзләренең гадилекләре вә тәҗрибәләре азлыгы сәбәбеннән, ата вә аналар яраклы күргән карашларга ризасызлык күрсәтсәләр, бу тәкъдирдә, өйрәнү юлы белән күңелләрендә булган шөбһәләрен бетерү һәм теләкләрен дә кузгату турында тырышу кирәк булыр. Ничек кенә булса да, балаларны ирексезләп өйләндерү ярый торган эш түгел, чөнки, ихтыяҗларыннан башка сатылып китәргә – алар мал түгелләр бит!..

Бер-беренә тәрбия җәһәтенчә канәгатьләнерлек, вә бер-берен ошаткан егет белән кызның никахларына фәкать фәкыйрьлеген сәбәп итеп күрсәтеп, ризалык бирмәгән ата вә аналар үз вазифаларын үтәгән булмаслар, чөнки, әхлагы гүзәл булган кешенең фәкыйрьлеге һич гаеп түгел. Малсыз кеше – кешесез малдан хәерле түгелме?..

■ **Ризаэтдин Фәхретдиннең «Гаилә» китабыннан**

# Гаилә вә хатын



Ир белән хатынның шәригать кушкан сурәттә бергә кушылуыннан, ягъни җан һәм тән бер булуыннан – гаилә төзелер.

Ир кешенең үзе өчен бер хатын сайлап алуы – дөньяда булган тереклегендә, шатлык вә кайгысында бер иптәш, икенче сүз белән әйткәндә, һәрбер ак вә кара көннәрендә сыеначак, кайгылы вакытта юатып, җанны рәхәтләндерәчәк бер сердәш табуы булыр.

Хатын кеше – адәм баласында холыкларны гүзәлләндерергә сәбәп булучы, каты күңелләрне йомшартучы вә кешеләрнең дуслашуларына бер сәбәпче, кешеләрне җанвар түгел, ә кеше итүче бер куәттер, чөнки дуслык вә якынлык кебек нәрсәләр никадәр нык булсалар да, гаилә төзүгә кодрәтләре җитмәс.

Шуңа нигезләнеп, хатын – хезмәтче түгел, бәлки гаиләдер. Бу сүздә арттыру бар дип уйланмасын! Чөнки ирләр – гаиләнең җитәкчеләре булган хәлдә, хатыннар – җитәкченең идарә итүендә булган гаиләнең нигез терәкләре вә өйнең идарә итүчеләре булырлар. Бу тәкъдирдә аларга «гаилә» дип әйтергә дөрес булыр.

Бөек бер затның әйтүенә караганда: хатын идарәсендә булмаган өйгә «өй» дип әйтү дөрес булмас, вә хатын идарәсендә булмаган бер өйдә утырганнарга да «гаилә» дип тә әйтелмәс.

Хатын яхшы булу шарты белән дөнья вә Ахирәтнең бәхетенә беренче сәбәп булганы кебек, һәртөрле рәхәт тә аның кулына ышанып тапшырылгандыр.

Изге хатын бетми торган хәзинә булганы кебек, бу дөнья сәфәрендә иренә юлдаш, мәшәкатьләрдә юатачак юаныч, авырлыкларда таяныч булыр.

Изге хатын иренең малын саклар. Иренең башына килгән хәсрәтләрне сүндерүдә көче бетмәс тәкъдирдә гайрәтле бер гаскәр кебек ирен юату турысында бөтен кодрәтен сарыф итәр. Күп вакыт булыр, кайбер нәрсәләрдә әйберне сак тотып, һичкемгә сиздермичә, азмы-күпме мал җыяр да, иң кирәк бер вакытта иренә чыгарып биреп шатландырыр.

Хатын – гаиләнең терәге, дигән идек. Әгәр дә гаилә пароходка охшатылса, шөбһәсез, хатын пароходның койрыгына охшар. Дөнья зурлыгында булган пароходлар, гизеп йөрүләрендә койрык хәрәкәтенә иярүләре кебек, дәүләт мисалында булган гаиләләр дә, гаилә эчендә булган хатын хәрәкәтенә иярәчәкләрдер. Ләкин пароход койрыгы команданның (башлык) кушуына күрә хәрәкәтләнгән хәлдә, хатын фәкать үзенең тәрбиясенә яраклы эсул белән хәрәкәт итәчәктер.

Күз уңыбызда булган милләтләрнең хәлләре, хатыннар хәлләре белән һәрвакытта тигез булуы, шушы дәгъваның дөрес икәнен исбат итәр. Мәсәлән, хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле; хатыннары тәрбиясез булган милләт – тәрбиясез; хатыннары тырыш вә идарә итүчән милләт – бай; хатыннары ялкау вә яки исраф итүчән милләт – фәкыйрь буладыр.

■ **Ризаэтдин Фәхретдиннең «Гаилә» китабыннан**

# ИСЛАМДА ИР-АТ ВАЗИФАЛАРЫ



Бүген сүз ир-атлар хакында барыр. Кем соң ул ир-ат? Аның нинди вазифалары бар?

Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә игътибар итсәк, анда «ир» сүзе болай аңлатыла: «Ир — борынгы төркиләрдә эр — сугышчы, яугир. Ир аты (исемен) алу өчен угыл ауда яисә яуда нинди дә булса батырлык күрсәтергә тиеш булган. Бүгенге татар телендә ир-ат — «ирләр» мәгънәсендәге җыйма сүз».

Димәк, элек-электән ир исеменә ирешү өчен, күпмедер дәрәҗәдә үз-үзеңне күрсәтергә яки нинди дә булса билгеле бер сыйфатларга ия булырга кирәк булган. Татарларда ир-атны элек-электән һөнәрле булырга, алынган эшләрен камил башкарырга, батыр, кыю булырга өйрәткәннәр. Балаларны шулай тәрбияләгәннәр. Татар халык мәкальләрен алып карасак, анда: «Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз»; «Яхшылыкка яхшылык – һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык – ир кешенең эшедер»; «Ил – иргә, ир илгә таяна» кебек мәкальләр күрербез.

Кайбер чыганакларда ирләргә аңлатманы «хатын-кызларга антоним, ягъни капма-каршы булган зат» дип тә бирәләр. Бу гади генә аңлатма булса да, моның да үз мантыйгы бар: хатын-кыз гаиләне эчтән саклый, ир-ат тышкы яктан; хатын-кыз нечкә күңелле, хискә бирелүчән, ир-ат – салкын акыллы; хатын-кыз 10 кг күтәрә, ә ир-ат – 50. Әмма бу – мәсьәләгә бер яктан килеп караганда гына шулай.

Инде Аллаһы Тәгаләнең китабы Коръәни Кәримгә игътибар итик. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

**«Һәм синең Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин, әлбәттә, җир өстендә Адәмне хәлифә итеп кылмакчымын».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:30

Аллаһы Тәгалә җир йөзендә хәлифә буларак Адәм галәйһиссәламне, ягъни ир-ат кешене урнаштырган. Зур дәрәҗә белән беррәттән, олуг җаваплылык та биргән. Димәк, Ислам буенча ир-ат бик җаваплы кеше булырга тиеш. Һәм бу ир-аттан бик күпне таләп итә торган сыйфат, чөнки җаваплы кеше үз өстенә йөкләнгән вазифаларның барысын да үтәргә тырышачак. Шул вазифаларны Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хәдисләреннән чыгып, санап үтик:

1. Күркәм холыклы булу. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләтү вәссәлләм бу хакта түбәндәге хәдисләрдә әйткән:

«Кулыннан һәм теленнән бүтән кешеләр имин булган кеше – мөселман була».

«Дөреслектә, нинди генә хәлләрдә дә йомшак булу – мөселманны бизи. Ә аның юклыгы (нинди генә эштә булмасын) – кешене каралта».

2. Калган кешеләргә яхшы мөгамәләдә булу. Бу хакта түбәндәге хәдистән чыгып әйтеп була:

«Һәрбер мөселман – икенче мөселман өчен кардәш, шуңа күрә ул аны беркайчан да кыерсытмаска тиеш. Берәү авыр вакытта кардәшенә булышса, аңа авырлык килгәндә Аллаһы Тәгалә Үзе булышыр. Кем бер кардәшен куркынычлыктан азат итсә, Аллаһы Тәгалә аны Кыямәт көнендәге куркынычлыктан азат итәр».

Бу пунктка тагын: кардәшең авырганда, аның хәлен белергә бару; вафат булганының җеназасын уку; чакырган кардәшнең чакыруын кабул итү; кардәшең белән күрешкәндә аңа сәлам бирү; үз кардәшеңә һәрвакыт яхшылык теләү; кардәше янында булганда да, булмаганда да аңа карата ихлас булу кебек вазифаларны кертеп булыр иде.

3. Пөхтә булу: кием, транспорт, йорт-җир һ.б.

Пәйгамбәребез ир-атларның матур булуларын яратып кына калмаган, ул һәрвакыт аңа чакырган да. Бер сәфәр вакытында ул сәхабәләренә: «Дөреслектә, сез үзегезнең кардәшләрегез янына барасыз. Шуңа күрә пөхтәләнегез, үзегезнең киемнәрегезне чистартыгыз, иярләрегезне матурлагыз. Сез аларның күңелләрендә чиста чишмәгә охшарга тиешсез», – дип әйтә. Әйе, мөселман кеше эчке яктан да, тышкы яктан да пөхтә булырга тиеш. Нинди дер яңа әйбер алырга акча җитмәгән очракта да, искенең кадерен белеп, чисталыкта тотарга тырышырга кирәк. Сәхабәләр заманын беләбез: Сәгъд бине Мөгаз атнага бер тапкыр өеннән чыкмый торган була. Шәһәр башлыгы булуга карамастан, кияргә бер генә киеме булган. Ул аны атнага бер тапкыр юып, аның кипкәнен көткән. Аннан соң кешеләр янына чыгып, идарә эшләрен дәвам иткән. Алмашка юк дип, атналар буе пычрак кием белән йөрмәгән.

4. Үз гаиләсен тәэмин итү, гаилә әһелләренә карата иң күркәм мөнәсәбәттә булу.

«Иң камилегез – холкы ягыннан иң күркәм булганыгыз. Ә иң яхшыларыгыз – үзенең хәләл җефетенә иң яхшы булганыгыз». Өйләнгән ир-ат, әлбәттә, үзенең хатынын, балаларын тәэмин итә. Өйләнмәгән булса, әти-әнисен кайгырта. Ничек кенә булмасын, ул гаиләле кеше булып санала һәм көченнән килгәнен эшләргә тиеш була. Нәкъ менә тиеш була: Коръәни Кәрим аятьләрендә һәм Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең хәдисләрендә әйтелгәнчә, ир-ат – гаиләне матди яктан тәэмин итүче, анда тәртип саклаучы һәм тормыштагы авырлыкларны чишүне үз өстенә алучы кеше. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһы Тәгалә ирләрне акыл һәм көч-куәт ягыннан хатыннардан өстен кылганга һәм алар байлыкларын хатыннарга сарыф иткәнгә күрә, ир-атлар – хатыннар турында кайгыртып торучылар».**

«Нисә / Хатыннар», 4:34

Шулай ук ир-атның гаиләдәге иң зур вазифаларының берсе – хатынына һәм балаларына да яхшы мөнәсәбәттә булу.

Ир-ат һәрвакыт ир булып калырга тиеш. Юкбардан тавыш чыгармаска, җаваплы булырга, гаиләне тәэмин итәргә тырышырга тиеш. Һәм әгәр дә хатынының берәр сыйфатын яратып бетермәсә дә, ул аны икенче бер сыйфаты өчен тагын да катырак ярата ала. Шуңа күрә, гаилә мөнәсәбәтләрен дә хикмәтле итеп алып бара белергә кирәк.

5. Гыйлемле булу. Аллаһы Тәгалә дә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә бу мәсьәләгә бик күп басым ясаганнар. Гыйлемле булу турында бик күп мәкаләләр язылган, бик күп вәгазьләр сөйләнелгән. Ир-ат дини гыйлем дә алырга, үзенең һөнәре буенча да камил гыйлемле булырга тиеш.

Дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле – пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам булган, дип әйттек. Шуңа күрә без – ир-атлар: «Безгә үрнәк күрсәтегез», – дип әйтсәк, иң беренче, Пәйгамбәребезгә карыйк! Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: ир-ат булу – кешегә кайбер «өстенлекләр» бирсә дә, масаер өчен бер генә дә сәбәп бирми, киресенчә, вазифалар гына өсти. Ир-ат дөрес итеп максатлар куярга һәм аларга ирешә белергә тиеш, ул башкаларны хөрмәт итәргә һәм үзе дә хөрмәтле булырга, ярдәмчел һәм үзенә күрсәтелгән ярдәмне кабул итә белергә, һәрвакыт үсәргә (һөнәри яктан, гыйлем ягыннан һ.б.), тәрбияле, күркәм әхлаклы булырга, ә иң мөһиме – тәкъва булырга тиеш. Аллаһы Тәгаләдән курыккан ир калганнарның да хакларына керергә, гөнаһлар кылырга, үз вазифаларын үтәмәүдән куркачак.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә өстебезгә йөкләгәннәрне башкарып чыгарга көч, дәрт, дәрман бирсә иде. Бу дөньяда да, Ахирәттә дә уңышларга ирешергә насыйп вә мияссәр кылса иде. Әмин!

■ **Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,**
Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы

# Намаз вакытлары турында

Һәр намазны үз вакытында уку – фарыз. Вакыты кергәнче укылган намаз фарыз намаз булып саналмый.

Вакытында укылмаган намазны соңыннан каза кылу – фарыз.

**Иртәнге намазның вакыты** – таң яктылыгы җәелгәннән башлап кояш чыга башлаганчыга кадәр. *Редакциядән:* бүгенге көндә махсус җәдвәл рәвешендә чыгарылган айлык «намаз вакытлары»нда яки сайтларда берничә бүлек күрсәтелә: сәхәр тәмам, мәчетләрдә укыла, кояш чыга. Иртәнге намазны «сәхәр тәмам» вакытыннан алып, «кояш чыга» бүлегендә күрсәтелгән сәгатькәчә укырга ярый. «Сәхәр тәмам» дип таң беленә башлаган вакыт күрсәтелгән, ә «мәчетләрдә укыла» дип аерым вакыт ир-атлар мәчетләргә җәмәгать намазына җыела алсын өчен билгеләнгән.

**Өйлә намазының вакыты** – кояш иң югары ноктасыннан авышканнан башлап, икенде намазы вакытына кадәр.

**Икенде намазының вакыты** – һәр әйбернең күләгәсе үзеннән ике мәртәбәгә зуррак булудан башлап, кояш тәмам батып беткәнчегә кадәр.

**Ахшам намазының вакыты** – кояш батып, тулысынча күмелгәннән башлап, шәфәкъ кызыллыгы беткәнчегә кадәр (шәфәкъ – кояш батканнан соң көнбатыш тарафларында күренә торган кызгылт яктылык).

**Ястү намазының вакыты** – шәфәкъ кызыллыгы беткәннән башлап, таң яктылыгы җәелгәнчегә кадәр.

**Витр һәм тәравих намазларының вакыты** – ястү намазы укылганнан соң таң атканчыга кадәр.

■ **Ә. Максудиның «Гыйбадәте Исламия» китабыннан**

# Башка кеше өчен ничек итеп дога кылырга?




Башка кеше өчен дога кылу Исламда кардәшлек билгесе булып тора һәм мондый ихлас доганы Аллаһы Тәгалә кабул итәр. Дин кардәшләребез, туганнарыбыз, дусларыбыз, остазларыбыз һәм, әлбәттә, әти-әниләребез өчен дога кылу хәерле вә кирәкле гамәл булып тора. Еш кына без яхшылыкка җавап итеп кешеләргә изге теләкләр телибез, Аллаһыдан аңа хәерлесен сорыйбыз. Мондый очракта махсус кылырга кирәк дигән догалар юк. Кайвакыт без кеше өчен бик конкрет әйберләр сорарга мөмкинбез: шул эшкә урнашса ярар иде, фәлән кызга өйләнсә иде, шул сәфәргә чыга алса иде һ. б. Болай сорау рөхсәт ителсә дә, без үзебез өчен дә, башка кеше өчен дә нәрсәнең хәерле булачагын белмибез. Бу серләр фәкать Аллаһыга гына ачык. Шуңа күрә, башка кеше өчен дога кылганда, аңа Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешүне, мөэмин-мөселман булып Ахирәткә күчүне һәм хәерлесен сорарга кирәк. Барча догаларыбыз ихлас булсын һәм Раббыбыз безгә бәрәкәт биреп, догаларыбызны кабул итсен!

■ **Islam-Today**



# Ни өчен бар халык мөселман түгел?



Аллаһы Тәгаләнең «Әл-Хәким», ягъни «Хикмәтле» дигән исеме бар. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең һәрбер гамәле Аның Үзенә генә хас хикмәт белән башкарыла. Кешеләрнең төрле милләт булып яшәүләрендә, аларның төрле телләрдә сөйләшүләрендә дә үзенә бер төрле хикмәт бар. Шундый гыйбарә бар: «Ничә тел беләсең, шуның кадәр кеше син». Бүтән тел өйрәнү, чит халыкның гореф-гадәте белән танышу – үзе бер күңелле вакыйга булып тора. Әйе, Аллаһы Тәгалә бар халыкны да бер телдә сөйләшә торган, бер дин тота торган бер милләт итә ала иде.

**«Әгәр Раббың теләсә иде, әлбәттә, җир йөзендәге кешеләр барчалары иман китерер иделәр. Син, Мөхәммәд галәйһиссәлам, барча кешеләрне ышандыру өчен, аларны мәҗбүриләр идеңме?»**

«Юныс», 10:99

Әмма Аллаһы Тәгалә кешеләрне барысын да баштан ук мөселман итеп кылмады, Ул кешеләрне дингә үз ихтыярлары белән килсеннәр дип, аларга сайлау мөмкинчелеге бирде. Моңа охшаш аятьләрне Коръәндә тагын очратып була һәм болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең хикмәте турында сөйли. Шулай ук, Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә дә бернинди мәҗбүриләү көче бирелмәгән иде. Мәсәлән, ул дога кылып, бар халыкның Исламда булуын сорый ала иде. Тик аннан соң аның җирдәге вазифасы да тәмам булыр иде. Әмма Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Расүл галәйһиссәламнең бурычы фәкать Аллаһы хөкемнәрен һич үзгәртмичә кешеләргә ирештерү генә. Аллаһы сезнең күрсәтеп һәм яшереп эшләгән эшләрегезне яхшы белә».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:99

Чыннан да, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәллям бу дөньяга күркәм чакыручы, дингә, тугры юлга дәшүче буларак кына килгән. Һәм ул үзенең эшен иң камил рәвештә башкарып чыкты да.

**«Диндә көчләү юк! (Моның кадәр дәлилләрдән соң) Туры юл адашканлыктан бик ачык аерылды. Кем дә кем тагутларны (шайтанны һәм потларны) инкяр итеп, Аллаһыга инанса, ул кубуы (сынуы, ватылуы ихтимал да) булмаган ышанычлы тоткага тотынган булыр. Аллаһы – (һәрнәрсәне) Ишетүче, (һәрнәрсәне) Белүче».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:256

Бу аяте кәримәнең мәгънәсенә күрә, беркем дә Ислам диненә керер өчен ирексезләренгә тиеш түгел. Әгәр мондый ирексезләү нәтиҗәсендә кем дә булса: «Мин мөселман булдым», – дип теле белән әйтсә, ләкин күңеле белән кабул итмәсә, Аллаһы хозурында ул мөселман булып саналмас. Бу мәгънәдә диндә көчләү юк.

Аллаһы Тәгаләнең дөньяга шуның кадәр пәйгамбәрләр җибәрүе дә дингә, бер Үзенә гыйбадәткә чакыруга бәйледер. Һәм бу очракта кеше тулысынча үз иркендә кала: нинди юл белән барырга, нәрсә ашарга, ни рәвешле акча эшләргә. Шушы хикмәтне аңлаган кеше, ин шә Аллаһ, бәхетле булыр, чөнки бәхетне дөрес җирдән эзлиячәк.

■ **Islam-Today**

# Хәләл булмаган ризыкны нишләтергә?

Кайвакыт мөселманнарга да харам ризыклар эләгергә мөмкин. Мисал өчен, кеше тыелган азык-төлекне, составында харам барлыгын күрмичә, кибеттән алырга, кунаклар алып килергә мөмкин.

Мондый ризыкны кешеләргә яки хайваннарга ашатырга ярамый.

Игътибар итегез, аларны фарызларны үтәмәүче мөселманнарга да, мөселман булмаганнарга да бирергә ярамый. Хәтта кешенең үзе мондый ризык сатып алуын яки ашавын белсәгез дә, сез аңа харам ризык бирергә тиеш түгелсез. Тыелган ризыкны ташларга кирәк. Бу исраф булачак дип борчылмагыз, чөнки исраф харам әйбергә карамый, «исраф» төшенчәсе хәләл әйберләргә карата гына кулланыла.

«Хәләл» билгесе булган ризыкларны алу сезне мондый очраклардан саклый ала, андый билгесе булмаган азык-төлекне алганда, һәр нәрсәнең составын җентекләп тикшерергә кирәк.

■ **halalrt.ru**

# «Нигезләмәгә таяну күп проблемаларны




Җомәдәл-әүвәл аеның 29 нчы көнендә, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында «ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә»: әһәмияте, өстәмәләр, гамәлгә ашыру перспективалары» дигән темага матбугат конференциясе уздырылды. Журналистларның сорауларына очрашуның спикерлары – Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы Булат хәзрәт Мөбәрәков җавап бирде.

Җәлил хәзрәт Фазлыев билгеләп үткәнчә, «ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә» – бик әһәмиятле һәм мөһим документ: «Нигезләмә имамнар арасында вак кына мәсьәләләрдә бәхәс, бүленеш килеп чыкмасын, бердәмлек булсын өчен, шулай ук урыннарда вәсвәсәләргә юл куймау максатыннан эшләнде», – диде ул.

Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин да имамнар арасында бу документка ихтыяҗ зур булганлыгына игътибар юнәлтте. Ул Нигезләмәнең беренчел варианты 2014 елда кабул ителүен искәртеп, документның хәзерге редакциясе шактый камилләштерелде, бүгенге көн ихтыяҗларын исәпкә алып, тулыландырылды, дип ассызыклады.

Рөстәм хәзрәт, журналистларның «Нигезләмәдә татар теленә кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан нинди урын бирелә?» дигән соравына җавап биреп: «Документта республика мәчетләрендә җомга һәм гает намазларының вәгазьләрен татар телендә алып барылырга тиешлеге аерым ачык язылган. Татар телен белмәгән кешеләргә бу телебезне өйрәнү өчен бер этәргеч булып торачак», – диде.

Булат хәзрәт Мөбәрәков әйтүенчә, Нигезләмә мөселманнарның көндәлек тормышындагы иң әһәмиятле гыйбадәтләрне, йолаларга кагылышлы хөкемнәрне әһле сөннәт вәл җәмәгать мәзһәбенә туры килгән бер тәртипкә сала. Ул ассызыклап узганча, никах һәм талак мәсьәләләре документның иң мөһим бүлекләре булып тора: «Бүгенге яшьләр бергә тормыш корганнан соң, гаиләне саклап калу мәсьәләсендә үзләрен җавапсыз тота. Моны истә тотып, нигезләмәдә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә салу хөкемнәре имамнарга, бигрәк тә казыйларга, өстәмә ярдәмче чаралар буларак формалаштырылды», – диде ул.

## «Исем дөрес булсын»

Нигезләмәнең исем кушу кагыйдәләре турындагы бүлеге дә игътибарга лаек. Аерым алганда, анда исемнең Ислам дине традицияләренә туры килергә тиешлеге ассызыклана. Әгәр дә баланың әти-әнисе Ислам принципларына каршы килә торган исем сайласа, имам аларга башка традицион мөселман исемен сайларга ярдәм итәргә бурычлы. Бу уңайдан Җәлил хәзрәт әлеге мәсьәләнең шулай ук бик мөһим булуын билгеләп, яңа туган сабыйга кушарга ярый торган исемнәрнең критерийларына тукталды.

– Исем дөрес булсын, ул татарча, гарәпчә яки фарсыча матур мәгънәгә ия булырга тиеш, – дигән теләген җиткерде ул. – Хәзер, гадәттә, туу турындагы таныклыкны бала тудыру йортында ук биреп кайтаралар. Анда инде сабыйның исеме язылган була. Шуңа күрә әти-әниләр, бала тудыру йортына барганчы ук, сабыйга кушыласы исем турында мулла белән киңәшләшсен иде.

## Өчесе, җидесе, кырыгы...

Журналистларны өчесе, җидесе, кырыгы, елы уңаеннан үткәрелә торган традицион искә алу мәҗлесләренә кагылышлы сорау да кызыксындырды. Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин Нигезләмәдә бу мәсьәләнең аерым бүлек буларак урын алуын билгеләп: «Шәригатьтә милләтнең дингә каршы килмәгән гореф-гадәтләре нигез булып санала. Әлеге мәҗлесләр – халкыбызның ислам дине кабул ителгән чордан ук сакланып килгән традициясе, шуңа күрә аларны үткәрү кирәк», – диде.

Моңа өстәп, Җәлил хәзрәт: «Мәҗлескә кунак җыеп сыйлау, вәгазь сөйләү, Коръән уку, садака бирү, дога кылу тыелмаган. Димәк, болар – бидгать түгел», – диде. Булат хәзрәт Мөбәрәков ачыклык керткәнчә, бидгать Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән билгеле булган Сөннәтне юкка чыгару дигәнне аңлата.

«Өчесен, җидесен, кырыгын, елын үткәрү татар халкы тарафыннан динне саклау факторы буларак билгеләнгән. Бу мәҗлесләрдә Аллаһы Тәгалә тыйган гамәлләр кылмасак, аларны үткәрү берничек тә бидгать була алмый», – дип әйтте ул. Булат хәзрәт Нигезләмәгә әлеге мәҗлесләрне уздыру вакытының да кертелүен, моның бу уңайдан кешеләр арасында бәхәс чыкмасын өчен эшләнүен әйтеп узды. Ул каршы фикердә булучыларга Голәмәләр шурасына мөрәҗәгать итәргә киңәш итте, барлык дәлилләребез бар, без бәхәскә һәрвакыт әзер, диде.

Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин имамнарның кабул ителгән Нигезләмәгә таянып, халыкка хезмәт итү нәтиҗәсендә ыгы-зыгыларга нокта куелачагына, күп проблемаларның хәл ителәчәгенә ышануын белдерде. Аның сүзләренчә, Нигезләмә имамнар эшчәнлегендә кулланыла торган төп документ булса, хәзерге вакытта нәзарәт тарафыннан мөселманнарның киң катламына юнәлтелгән «Фәтвалар китабы» әзерләнә. Анда Татарстан мөселманнары арасында иң киң таралган бәхәсле мәсьәләләр буенча чыгарылган фәтвалар урын алачак.

«ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә» быел гыйнвар аенда Татарстан Республикасында фикер алышулардан һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумында расланганнан соң, гамәлгә керде. Документ нигезле характерга ия, ул асылда Татарстанда сөнни Ислам традицияләрен саклау механизмын эшләтеп җибәрә. Документ расланганчы, Голәмәләр шурасы, Казыйлар шурасы, шәригать белгечләре 2014 елда эшләнгән Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү буенча бердәм рәвештә җентекле эш башкардылар. Нигезләмә Татарстанда дини һәм иҗтимагый өлкәдәге көнүзәк вәзгыятьне исәпкә алып яңартылды. Документ әзерләнгәндә гакыйдә һәм Хәнәфи мәзһәбе буенча классик хезмәтләр файдаланылды. Алга таба Татарстанның мөфтияттә аттестация узган имамнары үз эшчәнлекләрен әлеге Нигезләмә нигезендә алып барачаклар. Һичшиксез, документ шулай ук гади мөселманнарның – республиканың барлык мәхәллә әгъзаларының дини практикаларына кагылачак. Алар өчен документта мөселман йолаларын дөрес үтәү таләпләре буенча тулы мәгълүмат бар.

■ dumrt.ru

# Казан басмасы Төркиядә уңай бәяләнде

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте нәшер иткән Коръән басмасы Төркиядә Кыйраәт һәм Мосхаф (иск. Коръән атамаларының берсе) экспертизасы комитеты Идарәсенең уңай бәясен алды. Бу хакта мөфтияткә Төрек Республикасының Дин эшләре министрлыгында хәбәр иттеләр.

Экспертиза бәяләмәсендә билгеләп үтелгәнчә, «Казан Мосхафы» дип исемләнгән Коръән-Кәрим битләре дөньякүләм кабул ителгән «Әр-Рәсем Әл-Госмани» стандартлары нигезендә тикшерелгән. «Хаталар табылмады, барлык битләр дә бар», – диелә рәсми документта.

Кыйраәт һәм Мосхаф экспертизасы Комитеты Идарәсе Төркиядә 1889 елда оешкан. Әлеге структура Коръәнне хатасыз бастыруны, аның тәрҗемәләрен, шулай ук хаталы Мосхаф басмалары табылу очракларын күзәтә. Моннан тыш, Кыйраәт һәм Мосхаф экспертизасы комитеты Идарәсе эшчәнлеге өлкәсенә Кыйраәт турындагы фәнгә караган тикшеренүләр карый.

Татарстан Диния нәзарәте нәшер иткән Коръән басмасына Төркиядә эшләп килгән махсус оешма тарафыннан бирелгән бу уңай бәяләмә беренче түгел. 2017 елда мөфтият чыгарган Коръән басмасы Россиядә ислам үсеше тарихына кереп калды – ул рәсми рәвештә дөньякүләм стандартларга тәңгәл килә дип танылды. Коръән Сүриянең вакфлар министрлыгы каршындагы Коръән эшләре буенча Югары комиссиясе тикшерүен уңышлы үтеп, халыкара стандартларга яраклык турындагы Шәһадәтнамәгә ия булды.

Изге Китапны халык арасында популярлаштыру, тәфсирләр әзерләү, Коръән-хафизларның классик мәктәбен торгызу һәм иҗазалы хафизлар булдыру эшчәнлеген Диния нәзарәте җаваплы, күпьяклы, эзлекле һәм даими рәвештә башкара. Шул рәвешле, Татарстан мөфтияте Россиядә Коръәнне дөрес аңлауга корылган ислам хокукын үстерү өчен фундаменталь җирлек булдыру максатында мөһим эш алып бара. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы карары белән 2019 ел Тәфсир елы дип игълан ителде.

«Казан басмасы» – татар халкының тарихи бренды, Коръәннең дөньядагы иң яхшы басмаларының берсе. Татарларда Коръән бастыру традицияләрен торгызу өстендә дә мөфтият актив эшчәнлек алып бара.

■ **dumrt.ru**

# Рамазанга кадәр намазга өйрәнергә чакырабыз!



2 мартта Казанда «Ислам. Беренче адымнар» проекты башлана, анда катнашучылар намаз укырга өйрәнә һәм ислам нигезләренә төшенә алачак.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте әлеге интенсив курска кабат укучылар җыя башлавы турында игълан итә. Проект биш дәрес эчендә намаз уку күнекмәләрен һәм ислам нигезләрен тиз һәм нәтиҗәле рәвештә үзләштерү мөмкинлеген бирә. Гадәттәгечә, атна саен бер көндә бер темага багышланган дәрес үткәрелә. Шул сәбәпле, проект «бер көнлек мәктәп» дип тә атала башлады.

«Бер көнлек мәктәп» ислам кануннарын үтәп яши башларга теләгән, әмма дүрт ел дәвамында мәчетләр каршындагы курсларга йөрү өчен җитәрлек дәрәҗәдә буш вакыты булмаган кешеләргә юнәлтелә. Интенсив программа дәресләрне югары темпта һәм алдан билгеләнгән чикле вакыт эчендә бирә. Шул ук вакытта алынган белемнәр гамәлдә ныгытылачак, чөнки дәресләр мәчеттә уздырыла.

«Ислам. Беренче адымнар» проектының беренче дәресе 2 март көнне Казанның Галиев мәчетендә үтәчәк. Анда 14 яше тулган теләгән һәркем йөри ала. Дәресләр шимбә көннәрендә 9.00 дән 14.00 гә кадәр була.

Курс программасы үз эченә түбәндәге дәресләрне ала:

1. «Кереш дәрес». Терминология. Ислам динендә рөхсәт ителгән һәм тыелган гамәлләр. Тәһарәт.
2. «Намаз дәресе»: намаз уку тәртибе. Намазда укыла торган сүрәләр һәм догалар.
3. Ураза, зәкят, хаҗ.
4. «Гакыйдә дәресе»: иманның төп баганалары.
5. «Сира дәресе»: Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы.

Барлык дәресләр дә бушлай, укыту исә татар һәм рус телләрендә алып барылачак. Дәресләрне үткәрү планына укучыларга өйрәтә торган материалларны тарату да кергән. Проектта катнашкан һәркемгә бүләкләр өләшү каралган. Ислам нигезләрен өйрәнергә килүчеләрне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең тәҗрибәле хәзрәтләре һәм яшьләр хәрәкәте волонтерлары укытачак. Курсны узганнан соң, проектта катнашучылар исламның төп кануннарын үтәү өчен кирәкле белем багажына ия булачак. Моннан тыш, «Ислам. Беренче адымнар» проекты – аралашу даирәсен киңәйтү һәм сезнең кебек үк исламда беренче адымнарын ясаучы мөселманнар белән танышу мөмкинлеге дә.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты мөфтият тарафыннан беренче тапкыр 2018 елда гамәлгә ашырылды. Ислам динен өйрәнүдә беренче адымнарын ясаучыларга юнәлтелгән кыска вакытлы бу курслар тиз арада намаз укырга өйрәнү һәм ислам нигезләре белән танышу мөмкинлеген булдыра. Әлеге проектның ике сезоны дәвамында курсларга аша барлыгы 170 кеше, асылда, ислам кануннарын үтәп яшәүчеләргә әйләнгән мөселманнар, узды.

**Проектта катнашырга +7 (843) 237-86-18 телефоны аша язылырга мөмкин.**

■ **dumrt.ru**

## Әбү Хәнифәнең әтисе нинди булган?

Тарихчыларның күбесе Әбү Хәнифә 80 нче һиҗри елда туган, дигән фикердә торалар. Шулай ук, аның тууын 61 яки 72 нче елларда, дип фаразлаучылар да бар, ләкин күпчелекнең фикере дөресрәк булып санала. Үзләренең хезмәтләрендә күп кенә тарихчылар Әбү Хәнифәнең тумышына бәйле булган түбәндәге вакыйганы китерәләр:

Әбү Хәнифәнең әтисе – Сабит яшьтән үк бик тәкъва булган. Шулай бервакыт ул бер агымсу читендә тәһарәт алган. Шул чагында су агымына күз салып, суда бер алма йөзгәнен күргән. Алманы алып, ашаган. Тәһарәтен тәмамлап, авызында калган суларын төкергән чагында, ул төкерегендә кан күрә. «Мин ярамаган алма ашадым, ахрысы. Юкса авызым канамас иде», – дип уйлап куйган. Шуннан су агып килгән якка таба алма агачын эзләп киткән. Хуҗасын табып, булган хәлләрне сөйләгәннән соң, аңа алма өчен бер дирһәм акча биреп: «Гафу итегез мине, шелтәләмәгез», – дип әйткән. Аның тәкъвалыгын күреп, алмагачның хуҗасы болай дип әйткән: «Син миңа мең дирһәм түләсәң дә, мин сине гафу итмәм». Шуннан соң Сабит бу кешедән: «Мин үз хатамны ничек төзәтә алам?» – дип сораган. Хуҗа аңа болай дип әйткән: «Минем күрмәүче һәм ишетмәүче кызым бар, ул әле йөрми дә . Әгәр син аңа өйләнсәң, мин сине гафу итәрмен. Юкса, Кыямәт көнендә мин барысы өчен дә түләттерермен». «Бу дөнья авырлыклары, мәшәкатьләре – вакытлыча, бакыйлыкның газаплары – мәңгелек», – дип уйлап, Сабит ризалашырга булган. Хатынын беренче тапкыр күргәч, ул бик нык гаҗәпләнгән, чөнки аны күзләре күрүче һәм ишетүче кыз каршы алган. Ул Сабитка: «Мин фәләннең кызы – синең хатының», – дип әйткән. Сабит тагын да гаҗәпләнеп: «Син бит әтиең әйткән кызга охшамагансың, ул бит сине бөтенләй башкача тасвирлап бирде», – дип әйткән. Моңа карата кыз болай җавап биргән: «Әйе, әтием сиңа дөресен сөйләгән, чөнки мин еллар буе өемнән чыкмадым, чит кешеләрне күзгә дә күрмәдем һәм берниндигит кеше белән дә сөйләшмәдем». Эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап, Сабит дога кылган: «Бездән кайгы-хәсрәтне алган Аллаһы Тәгаләгә мактау булсын. Раббыбыз – Гафу итүче һәм Юмарт».

Кайбер тарихчылар бу риваятьне инкяр итәләр. Ләкин Әбү Хәнифәнең тәкъвалыгына күз салсак, бу риваятьнең хаклыгына инанабыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Үзегезгә хатын сайлаганда иътибарлы булыгыз, каны (геннар) кая тартасын белеп булмый бит», – дип әйткән сүзләре дә шуны күрсәтә. Әбү Хәнифә тәкъвалыкка нәкъ менә шул рәвешле ирешкән, күрәсең.

# Бишенче тугры хәлифә – Гомәр бине Габделгазиз

### Нәселе

Гарәп хәлифәлеге тарихында күпчелек тарихчылар тагын бер хәлифә – Гомәр бине Габделгазиз (Гомәр II) – идарә иткән дәверне аерып карыйлар. Дәүләт белән идарә итүдә күрсәткән хезмәтләре һәм үзеннән алда идарә итүчеләрнең эшчәнлеген намус белән дәвам иттергәне өчен аны «бишенче тугры хәлифә» дип атыйлар.

Гомәр бине Габделгазиз 680 елда (кайбер чыганакларда 682 елда) Мәдинәдә дөньяга килгән, Гомәр бине Хаттаб нәселеннән.

Гомәр бине Габделгазизнең әтисе – Габделгазиз бине Мәрван, өмәвиләр хәлифәсе Габделмәликнең ир туганы булган. Әтисе Мисыр әмире итеп билгеләнгәч, улын үзе белән Мисырга алып китәргә теләгән, ләкин Гомәр гыйлем алырга теләп, әтисенең тәкъдименнән баш тарткан.

### Мәдинә әмире булуы

Мәдинәдә укыганнан соң, әтисенең авыруы сәбәпле, ул кире Мисырга кайтырга мәҗбүр була. Улы кайтканнан соң, әтисе озак яшәми, вафат була.

Шуннан соң ул Димәшкъка күчә. Анда ул Габделмәлик абзасының тәрби-ясендә яши. Абзасы аны үзенең кызы Фатыймага өйләндерә.

705 елда Габделмәлик вафат булгач, аның урынына хәлифә булып улы Вәлид килгән. Ул Гомәрне хәлифәлектән читләштерү өчен, аны Мәдинәгә әмир итеп билгели. Гомәр Мәдинәгә кайтуына бик сөенә.

6 ел әмир булу дәверендә Гомәр зур эшләр башкара: яңа юллар салына, авыл хуҗалыгы эшләре өчен каналлар һәм коелар казыла. Шуннан соң, бу вазифаны калдырып, ул хәлифәлек гаскәрендә гади солдат булып хезмәт иткән.

Вәлид вафат булганнан соң, хәлифәлек аның энесе – Сөләйман бине Габделмәликкә күчә. Сөләйман белән Гомәрнең мөнәсәбәтләре яхшы булу сәбәпле, ул Гомәрне кире хәлифәлеккә чакыртып ала һәм аны үзенең ярдәмчесе итеп билгели.

### Хәлифә вазифасын үз өстенә алуы

Сөләйман озак вакыт хәлифәлек итә алмаган. Авырып, үлем түшәгенә яткач, ул хәлифәлекне кемгә калдырырга, дип уйлана башлаган. Вәзирен чакыртып, аның белән киңәшләшкән. Вәзире Гомәргә ишарә иткән. Ләкин моңа киртә булып Сөләйманның әтисе Габделмәликнең васыяте торган. Аның васыяте буенча, Гатика исемле хатынының Язид бине Габделмәлик исемле улы хәлифә булырга тиешле. Ләкин Сөләйман үз вәзиренең киңәшен тотып, васыять язган. Ул васыять буенча, иң элек Гомәр бине Габделгазиз, аннан соң Язид бине Габделмәлик хәлифә вазифасына билгеләнергә тиешле булган.

### Гомәр бине Габделгазизнең хәлифәлеге

Гомәр хәлифә булгач, үзенә һәм туганнарына хаксыз кергән малларны хәлифәлек казнасына кайтарган. Бу гамәлне ул үзеннән башлый. Бөтен үзенең һәм хәлифә сараеның зиннәтләрен казнага кайтарган. Ул тулаем купшы тормыш рәвешеннән баш тарткан. Өмәвиләрнең зиннәтле сараен ташлап, гади генә бер йортта яшәгән. Үзенең барлык мал-мөлкәтен хәлифәлек казнасына сарыф иткән. Хәлифә булган көнне аның еллык хезмәт хакы кырык мең динар булса, үлгән көнне дүрт йөз динар гына тәшкил иткән.

Шулай ук ул үзенең хатынына да: «Әй, Фатыйма, сайла, яки син үзеңнең зиннәтләреңне казнага кайтарасың, яки инде миңа сине талак кылырга рөхсәт ит. Мин бу малның өебездә булуын теләмим», – дип әйткән. Хатыны озак уйламыйча, алтыннарын, үзенең барлык зиннәтләрен казнага кайтарган. Гомәрнең бердәнбер кереме – Сувәйдә шәһәрендәге җир биләмәсе булган, анысы да елына бары тик 200 динар гына китергән.

Гомәр бине Габделгазиз идарә иткән дәвердә хәлифәлектә гаделлек хөкем сөргән, мөселманнарда мал күбәеп киткән. Ярлыларга үзләренең тормышларын яхшыртырга мөмкинлекләр тудырылган. Гомәр бурычлыларга үзләренең әҗәтләрен кайтарырга булышкан, ярлылык сәбәпле өйләнә алмаучыларга акчалата ярдәм иткән. Йортлары булмаган кешеләргә йорт салырга, утырып йөрергә хайваны булмаган кешеләргә утырып йөрер өчен хайван алып бирергә кушкан.

Гомәр бине Габделгазиз ил белән гадел идарә итеп кенә калмаган, ул галим дә, хафиз, дин белгече һәм мөҗтәһид тә булган. Ул мәчетләрдә михраблар (Мәккәгә таба юнәлешне күрсәткән мәчетнең эчке диварындагы уем) ясый башлаган. Коръәнне өйрәнүгә бик зур игътибар биргән һәм башкаларны да шуңа өндәгән. Гомәр идарә иткән дәвердә хәдисләрне язып ала һәм җыя башлаганнар.

Гомәр бик тәкъва һәм нык гыйлемле кеше булган. Һәрдаим Аллаһы Тәгаләгә сыенып, Аңа гыйбадәт кылган, булганына канәгатьлек белдереп, шөкер иткән.

### Гомәрнең вафат булуы


Гомәр бине Габделгазиз өч елга якын идарә иткәннән соң, аның кинәт сәламәтлеге начарлана. Кайбер чыганакларда, аның яман шеш авыруыннан газапланганын әйтәләр, ә берәүләрендә исә үлемен агулану сәбәпле дип күрсәтәләр. Гомәр өмәвиләрдән хаксыз алынган малларны казнага кайтара. Шул сәбәпле, алар аңа агу эчерәләр. Үлеме алдыннан Гомәр бик күп тапкыр Коръәни Кәримнең түбәндәге аятен кабатлый:

**«Без Ахирәтне, иман китерүдән вә Аллаһыга итагать итүдән олугланмаган һәм җир өстендә бозыклык фәсәд кыйлмаган хак мөэминнәр файдасына кылырбыз. Аллаһыга карышудан гөнаһлы булудан сакланучы мөэминнәргә эшенең ахырында уңыш, Ахирәттә бәхет булыр».**

«Касас / Хикәя», 28:83

Гомәр бине Габделгазиз һиҗри белән 101 нче елда (милади белән 720 ел) раҗәб аеның беренче көнендә 40 яшендә вафат булган. Ул Димәшкъта, Бидияр шәрки дип аталган урында җирләнгән.

# «Әр-Рәхман» сүрәсендәге кайбер нигъмәтләр




Бөек китап – Коръәни Кәрим әле бүгенге көндә дә иң еш укыла торган китап булып санала. Күпме мөселман аны биш вакыт намазда яттан укыйлар, дөньяның төрле почмакларында мәчетләрдә бертуктаусыз Коръән-хафизларыбыз аны хәтем чыга. Һәм Коръәни Кәрим Кыяматкә кадәр үзгәрмичә саклана торган бер могҗиза да булып тора.

Коръәни Кәрим үзе бер нигъмәт, ә андагы сүрәләрдә Аллаһы Тәгалә кешеләргә биргән тагын бик күп нигъмәтләр искә алына. Шундый сүрәләрнең берсе – «Әр-Рәхман». Аллаһы Тәгалә бу сүрәне Үзенең бик күркәм бер исеме – «Әр-Рәхман» – дип башлый да. Коръәнне тәфсир кылучылар «Әр-Рәхман» исеменең дәрәҗәсе бик югары диләр. Ул исемне нибары Аллаһы Тәгаләнең Үзенә генә әйтеп була. Калган исемнәргә килгәндә, кайбер исемнәрен кулланып, без кешеләрне дә сыйфатлый алабыз, мәсәлән, кешегә карап: «Нинди рәхимле кеше икән», – дип әйтеп була. Әмма: «Нинди рәхманлы кеше», – дип әйтмибез.

Татар телендә «Әр-Рәхман» сүзе «Рәхимле» дип кулланыла. Шуңа күрә дә «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» кәлимәсе «Рәхимле вә Шәфкатьле Аллаһы исеме белән» дип тәрҗемә ителә.

Рәхимле Зат – Аллаһы Тәгалә – бу сүрәдә Үзенең колларына биргән бик күп нигъмәтләрне искә ала һәм шуннан соң еш кына: **«Ий, кеше вә җен, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялган дип саный аласыз?»** – дип сорау бирә.

## Коръән нигъмәте

Аллаһы Тәгалә икенче аятьтә үк: «Коръәнне өйрәтте», – дип әйтә. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Коръәни Кәрим иң зур могҗиза, иң зур нигъмәт булып тора. Кешеләргә туры юлны тасвирлый торган, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә дәлил булып торган китап ул. Юкка гына Коръәни Кәримне дини һәм дөньяви бәхетнең чыганагы дип атамыйлар. Бүгенге көндә дә андагы аятьләрне дини булмаган галимнәр өйрәнер өчен, мөселманнар гыйбрәт һәм гыйбадәт, авыру кешеләр сихәт табар өчен укыйлар. Кешелек тә, җеннәр дә бу нигъмәт өчен бик күп шөкерләр әйтергә тиеш.

## Кеше – үзе бер нигъмәт


Алга таба Аллаһы Тәгалә кешене барлыкка китерү һәм аны фикерләргә, шул фикерләрен төрле рәвештә аңлата белергә өйрәтүне әйтеп уза. «Тин» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә: **«Тәхкыйк, Без адәм баласын күркәм сурәттә халык кылдык»**, – дип әйтә.

«Тин / Инҗир», 95:4

Аллаһы Тәгалә кешене күркәм сурәттә яратты, аның тәнен камил, органнарын көчле һәм үз вазифаларын бертуктаусыз башкара торган итеп кылды. Аллаһы Тәгалә без кешеләрне Җир йөзендәге калган затлардан өстен итеп, акыл нигъмәте белән бүләкләде. Аллаһы Тәгалә кешене фикерләргә, тел белән сөйләшергә, кулы белән язарга өйрәтте. Шуңа күрә кеше үзенең фикерләрен аңлаешлы итеп әйтә ала. Шулай ук, кеше укый да белә һәм болар барысы да кешегә зур нигъмәтләр булып тора. Аллаһы Тәгалә «Әл-Мүлек» сүрәсендә болай дип әйтә: **«Әйт: «Ул – Аллаһы сезне юктан бар кылды вә сезгә хак сүзне ишетер өчен колак бирде, вә гыйбрәтләрне күрер өчен күз бирде, вә фикерләп, хак белән батылны аеру өчен күңел бирде, бу нигъмәтләргә сезнең шөкер итүләрегез бик аздыр».**

«Мүлек / Патшалык», 67:23

## Ай һәм кояшның хикмәте



5 нче аятьтә: **«Кояш вә ай билгеле бер үлчәү белән үз юлларында йөриләрдер»**, – дип әйтелә. Космос никадәр генә зур күләмле булмасын, андагы бар җисем дә билгеле бер тәртип белән хәрәкәт итә. Безнең Җир шарыбыз да искәрмә булып тормый, чөнки ул да шул космосның кечкенә генә бер кисәге. Кешелек дөньясы космосны элек-электә өйрәнгән, узган гасырның 60 нчы елларында бу өлкәдә тагын да зур мөмкинлекләр ачылды: без ачык космоска чыга башладык. Әмма безгә бу киңлекне өйрәнергә дә өйрәнергә әле. Аллаһы Тәгалә безгә планеталарның һәм йолдызларның хәрәкәтен аңлатып: **«Кояшның айга ирешүе һәм кичнең көндездән элек килүе дөрес түгел, ягъни бу эш булмас; Кояш белән Ай һәм башкалары һәммәсе һава бушлыгында үз юллары буйлап йөзеп йөриләр»**, – дип әйтә.

«Йәсин», 36:40

«Йәсин» сүрәсендәге бу аять Коръәннең Аллаһы Тәгаләдән иңгән китап икәнлегенә дә бер дәлил булып тора, чөнки планеталарның бернәрсәгә дә «бәйләп» куелмыйча, космоста, ягъни буш һавада билгеле бер орбита буенча хәрәкәт итүләре турында элек яшәгәннәр берничек тә белә алмаганнар.

Дөньяви галимнәрнең сүзләренә караганда, Җир шары өчен иярчене булган Ай да, аңа җылылык һәм яктылык бирә торган Кояш та бик зур әһәмияткә ия. Алар булмаса, Җир шарында яшәү була алмас иде, дип әйтелә. Аллаһы Тәгалә аларга билгеле бер вакытка кадәр үзләренең вазифаларын башкарырга боерган. Һәм, Аллаһыга шөкер, кояшның бер генә көн дә соңгарак калып чыкканы юк. Төн уртасында кинәттән көн, ә көн вакытында төн булмый. Болар турында газетабызда тулырак алдагы саннарда да сөйләшеп китәрбез әле, ин шә Аллаһ.

## Үсемлекләр дөньясы



Сулый торган һавабызның чисталыгына, кислородка бай булуына зур өлеш керткән үсемлекләр – җирдәге тереклекнең мөһим бер чылбыры булып торалар. Гомумән, җирдәге яшәештә үсемлекләрне, хайваннарны, кешеләрне аерып чыгарып булыр иде. Беренче икесенә яшәр өчен кешенең булуы шарт түгел. Әмма кеше өчен үсемлекләр дә, хайваннар да кирәк. Аллаһы Тәгалә кешеләрне алардан да өстен итеп яратып, аларны кешегә буйсындырган. Әмма шуны онытмаска кирәк: алар – Аллаһы Тәгаләнең мәхлукълары һәм алар үзләренә карата хөрмәтле карашка лаеклы. Агачларны, үсемлекләрне саклый белергә, аларны арттырырга тырышырга кирәк. Алар Аллаһыга буйсынган һәм Аңа итагать итәләр, шуңа да Аллаһы Тәгалә 6 нчы аять итеп: «Үләннәр һәм агачлар Аллаһыга сәҗдә кылалар», – дип әйтә.

Агачлар нык гәүдәле булганлыктан, ничек сәҗдә кылалар соң, дип сораучыларга, Аллаһы Тәгалә «Умарта кортлары» сүрәсенең 48 нче аятендә: **«Аллаһы бар иткән һәрнәрсәгә карап гыйбрәтләр алсагызчы, ул нәрсәләрнең уңыннан да, сулыннан да күләгәләре йөрер, вә түбәнчелек белән Аллаһыга баш иеп, Аңа итагать итәрләр»**, – дип җавап бирә. Ягъни агачлар үзләренең күләгәләре белән Аллаһыга сәҗдә кыла алалар икән.

## «Аллаһы күкне күтәрде һәм һәрнәрсәгә гаделлек белән үлчәү куйды»

Аллаһы Тәгалә өстебезгә күкне бина кылды. Күк – болытлар «йорты», күк – җирнең калканы, күк – кошлар, самолетлар юлы һ.б. «Гаделлек белән үлчәү куйды», ягъни гадел кануннар урнаштырып, кешеләргә һәр эшләрендә, һәр сүзләрендә гадел һәм туры булырга әмер бирде. Монда гади үлчәүләр турында гына сүз бармый, кеше һәрвакыт: үлчәгәндә дә, сөйләшкәндә дә, хөкем чыгарганда да, бәхәсләрне чишкәндә дә гадел һәм риясыз эш итәргә тиеш.

* * *

Аллаһының нигъмәтләрен санап карасак, һич санап бетерә алмабыз. Чыннан да, акылы камил булган кеше аларны кабул итә һәм берсен дә кире кага алмый. **«Ий, кеше вә җен, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялган дип саный аласыз?»**

■ **Габделхәким Фәсхиев**

# Күренекле мәгърифәтчебез киңәшләре

**14 февраль – күренекле галим, язучы һәм татар халкының мәгърифәтчесе туган көн. Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы) 1825 елда Зөя өязенең Олы Шырдан авылында дөньяга килә.**

Әлеге күренекле шәхес күпләребезгә язучы, фольклор җыючы, дару үләннәрен өйрәнүче буларак таныш булырга мөмкин. Шулай ук без аның тирән фикерле мөгаллим, тәрбия буенча китап авторы, дин өлкәсендә дә хезмәт куйган галим булуы белән горурлана алабыз. Мәсәлән, 1886 елда Каюм Насыйри «Мифтәх Әл-Коръән» дип аталган сүзлеге өстендә эшен тәмамлый. Бу үзенчәлекле сүзлектә 46 200 тирәсе сүз тупланган, галим аларны әлифба тәртибендә урнаштырып, аларның кайсы сүрәдә һәм Казанда басылган Коръәннең кайсы битендә килүен күрсәткән. Габделкаюм Насыйриның бу хезмәте – Коръән буенча төзелгән мондый беренче сүзлек.

Галимнең балалар һәм ата-аналар өчен язган гаять файдалы «Тәрбия китабы»ннан кайбер киңәшләр белән танышып китик.

### Унөченче тәрбия

Шәех Сәгъди әйткән икән: «Хаҗда Габделкадыйр Гилянины күрдем. Кәгъбәгә башын куеп яткан: «Әй ходаем, гафу ит! Әгәр гафу итмәсәң, Кыяməттә күзсез итеп каберемнән кубар: изге кешеләр арасында оятка калганымны күрмәсәм иде!» – дип әйтеп тора икән.

Әй улым, дөньяда бер кечкенә генә гаебеңне дә кешеләр күзенә күрсәтергә оялаеың. Кыямәттә, пәйгамбәрләр, изгеләр һәм бөтен дөнья халкы күз алдында гаепләреңне һәм гөнаһларыңны йөзеңә бәрсәләр, анда бит качарга урын булмаячак. Инде сиңа тәрбия булыр: ахирәттә йөзеңә чыгарлык гаепне эшләмә. Габделкадыйр Гиляни кебек изге кешеләр шул кадәр курыкса, сиңа, миңа ни кала?! Иманлы булу фарыздыр.

### Егерме тугызынчы тәрбия

Бер көчсез, зәгыйфь балыкчының кармагына бик зур балык эләкте. Балыкчы ул балыкны тартып чыгара алмады: көче җитмәде. Балык кармакны өзеп качты. Башка балыкчылар, моны күреп, әрләделәр һәм шелтәләделәр: «Һи, ачык авыз, кармагыңа эләккән шундый балыкны ычкындырдың!» – диделәр. Балыкчы әйтте: «Әй, егетләр, миңа насыйп булмагач, мин нишли алам? Һәм балыкның да көне бетмәгән», – диде.

Балыкчы насыйп булмаган балыкны тоталмый.

Балыкның әҗәле җитмәсә, кармакка эләкми.

Шулай инде, халык арасында гел фәкыйрь шелтәгә тарый.

### Утыз җиденче тәрбия

Шәех Сәгъди риваять иткәндер ки, бер фәкыйрь адәм бар иде, гомерендә бала күрмәде, Аллаһы Тәгаләдән сорады: «Әгәр улым булса, шушы өстемдәге киемемнән башка, милкемдә нәрсә юктыр, аны сатып фәкыйрьләргә өләшер идем», – дип нәзер әйтте. Бәс, Аллаһы Тәгалә аңа бер ул бирде. Бик шатланып, әйткән нәзерне тотты, фәкыйрьләргә хәер өләште. Берничә елдан, кабат Шам сәфәреннән кайтканда, юлым шул шәһәргә туры килеп, ул кеше турында сораштым. Әйттеләр, зиндандадыр, дип. «Ни сәбәпле зинданга төште?» – дип сорадым. «Улы бервакытны хәмер эчеп, сугышып, бер адәмне үтереп, шәһәрдән качкан иде. Улын тапмагач, аның урынына атасын зинданга салдылар». Әй улым, ошбу заманабызда да моңа охшашлы вакыйгалар бардыр ки, нинди байлар бар, балалары яшь һәм кечкенә заманда, кырык-илле мең, йөз мең белән сәүдә кылалар. Балалары үсеп җиткәч, фәкыйрьлек һәм мохтаҗлыкка калалар. Ул нидәндер? Әлбәттә, кечкенә вакытта балаларына яхшы тәрбия бирә белмәгәнлектән.



### Илле бишенче тәрбия

Әй улым, бер кеше сине явыз холкы белән рәнҗетсә, әчкерсезлегең белән аны гафу кыл, ягъни аннан ачу алам, дип мәшәкать чикмә. Егетлек һәм кешелеклелекнең ахырындадыр ки, һәрни тизлектә булса да, башкаларда булган хакыңны онытсаң. Башканың синдә булган хакын хәтереңдә тотсаң, моны егетлек диярләр. Үч алырга һәм җәза бирергә көч җитә торып гафу итү – барча изге холыкларның күркәмрәгедер.

### Алтмыш дүртенче тәрбия

Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр һәм яманрактыр, ягъни телдән әйтелгән ачы һәм кабәхәт сүзләрнең кешегә тәэсире тәнеңне пычкы белән кискәннән дә ачырактыр. Әй, улым, һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма, ни яман сүз әйтмә. Адәмнең җанына тия торган сүз әйтмә. Әмма бер сүзне син кирәк дип санап әйтерсең дә, кешенең күңеленә бик каты тияр. Әй, улым, каты сүзле булма. Изге холык белән һәм йомшаклык белән татлы сүзләр сөйләшү ризыкның ачкычыдыр, дияләр. Яхшы һәм йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китәдер. Кешегә ашыгып сүз әйтмә һәм ашыгып җавап бирмә.

### Җитмеш җиденче тәрбия

Һәм әгәр бер дустың яки карендәшең малын яки хезмәтен сиңа тапшырса һәм әманәт итсә, үз малың кебек итеп сакла, һәм үз хезмәтең кебек итеп башкар. Ул сәбәпле Аллаһы Тәгалә синең малыңа бәрәкәт бирер, һәм халык арасында әманәткә тугры булып танылырсың. Әмма, әй улым, малыңнан бер нәрсәне бер кешегә әманәт куям дисәң, исраф итүче кешегә әманәт куйма. Дәхи комарлы, ягъни отыш уен уйнаучы кешегә һәм хәмер эчүчегә әманәт куйма.

### Туксан бишенче тәрбия

Әй, улым, аш алдыннан бисмилләһ әйт, ашагач нигъмәтең хәлал булыр. Әмма харам нигъмәткә бисмилләһ әйтү тыела. Ә хәлал нигъмәткә бисмилләһ әйтмәсәң, ашаган азыгың шәйтан белән уртак булыр. Бисмилләһне аваз белән әйтү тиешледер, табын артындагы башка кешеләрнең дә исләренә төшерү буларак. Ашап туйгач, «әлхәмдүлилләһ» дип, шөкер итәргә кирәк. Әмма «әлхәмдүлилләһ» дип әчтән генә әйтү тиешле, башкаларны әле туймаган кешеләрне тукталырга мәҗбүр итмәсен.

### Йөз бишенче тәрбия

Бер хәким үзенең улына әйтте: «Әй ,улым, кемне теләсәң, аның белән сөйләш, мөгамәлә кыл, йөреш, кунакка чакыр, үзең бар. Әмма биш төрле кеше белән аралашма. Әүвәл ялганчы кеше белән әңгәмә кылма, чөнки ялганчының сүзе су өстенә ялган язу кебектер, ышанычы юктыр, якынны ерак кылыр, еракны якын итәр. Дәхи ахмак һәм надан белән иптәш булма. Чөнки ахмак кеше сиңа файда иткән кебек күренсә дә, чынлыкта, зарардыр. Һәм дәхи комсыз кеше белән аралашма. Чөнки ул кеше гел синнән өмет итеп кенә торыр. Янә дәхи саран кеше белән юлдаш булма. Чөнки саран кеше сиңа һичбер зарардан хали булмас. Әгәр дә аңар хаҗәтең төшсә, сине кимсетер һәм хур итәр. Хосусән, сәфәрдә саран кеше белән юлдаш булма. Дәхи дә куркак һәм җебегән кеше белән аралашма, чөнки куркак кеше белән һич имин булмассың.

### Йөз уникенче тәрбия

Әй улым, өч нәрсә күңелне шатландырыр һәм акылны саф кылыр: гүзәл хатын, җитәрлек кадәр ризык һәм якын дус, карендәш. Дәхи дүрт нәрсә бардыр ки, адәм аны чиктән тыш күп кылса, һәлак буладыр: чиктән тыш хатын белән маташса адәм һәлак буладыр. Янә явызлык артыннан күп йөри торгач, адәм һәлак буладыр. Дәхи күп отыш уйнаса, адәмнең юкка чыгуы андадыр. Дәхи дә күп хәмер эчсә, һәлак булмай калмыйдыр.

# «Һәр тере мәхлукъны судан халык кылдык»



Әгәр теләсә кемнән: «Кешелек һәм, гомумән, Җирдәге тереклек нинди чыганактан башка яши алмый?» – дип сорасаң, барысы да бертавыштан «су», дип җавап кайтарыр. «Су – яшәү чыганагы», дип юкка гына әйтмиләрдер. Кешенең тәне 75-80% судан тора. Әгәр кеше ризыктан башка бер айга якын яши алса, судан башка ул берничә тәүлек кенә яши ала. Су планетада бер үк вакытта өч төрле халәттә була алган бердәнбер матдә: сыеклык рәвешендә, газсыман – пар хәлендә һәм каты – боз хәлендә. Планетабызның туксан җиде процентын океаннар тәшкил итә, бу, шулай ук, су. Коръәндә дә Аллаһы Тәгаләнең барлык тереклекне судан барлыкка китергәнлеге турында әйтелә.

**«… җир һәм күкләр бергә кушылган иделәр. Без аларны аердык вә һәр тере мәхлукъны судан халык кылдык».**

«Пәйгамбәрләр», 21:30

Шулай ук, икенче бер сүрәдә кеше яшәеше өчен кирәкле булган нәрсәләрне су ярдәмендә ала, дип әйтелә. Су булганлыктан, безнең җирләребездә төрле җимешләр, үсемлекләр үсә.

**«Ул Аллаһы, күктән яңгыр суын индерде, ул су белән һәртөрле үсемлекне җирдән чыгарып үстердек һәм һәр үсә торган табигатьне яшел төстә җирдән чыгардык, алардан берсе өстенә икенчесе тезелеп үскән орлыкларны вә җимешләрне чыгарабыз, янә күп җимешле ботаклары җиргә якынлашкан хөрмә агачларын үстерәбез һәм дә йөзем, зәйтүн, анар бакчаларын үстерәбез, ул җимешләр төсе вә тәме белән кайберләре бербер сенә охшаган булыр, әмма кайберләре бербер сенә охшамаган булыр. Аларны җимешләнгән вә өлгергән вакытларында карагыз! Ничек гаҗәеп җимешләнәләр һәм пешеп өлгерәләр, дөреслектә, ул җимешләрнең шулай өлгерүендә – ышанучы кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен белергә дәлилләр бар».**

«Әнгәм / Терлек», 6:99

«Әл-Бәкара» сүрәсенең 22 аятендә дә искә алына:

**«Сезне халык кылучы – Аллаһы – сезгә җирне түшәк кылды, өстегезгә күкне бина кылды, күктән яңгыр индереп, сезгә ризык булсын өчен төрле җимешләр, игеннәр үстерде».**

Ислам динендә суның төрле шартларда кулланылышын беләбез. Ул нәҗесләрне юкка чыгару һәм тәнне пакьләү чарасы буларак та кулланыла.

Су – пакьләнү чарасы, дидек. Ислам дине – хак һәм бик пакь дин. Аллаһы Тәгалә бәндәләренә һәрчак пакь булырга боера. Мөселман булган кешенең күңеле яман сыйфатлардан һәм явыз фикерләрдән; тәне, киеме, йорты, ашаган ризыклары, эчкән сулары һәрбер нәҗестән пакь булырга тиеш. Намаз укыганда һәм башка гыйбадәтләрне кылганда мөселманга бигрәк тә пакь булу зарур.

Намаз укыр алдыннан кешегә тәнен, киемен һәм намаз укыласы урынын һәртөрле нәҗесләрдән пакьләү һәм шәригать боерганча тиешле әгъзаларны су белән юып, тәһарәт алу фарыз. Коръәни Кәримдәге «Мәидә» сүрәсенең 6 аятендә дә бу турыда әйтелә:

**«Ий мөэминнәр! Әгәр намазга басарга теләсәгез, башта тәһарәт алыгыз, ике кулыгызны терсәкләре белән һәм битегезне юыгыз, кулыгызны юешләп башыгызны сыйпагыз һәм дә аякларыгызны тубыклары белән юыгыз».**

Кайбер очракларда тәнне тулысынча юу (госел) таләп ителә: «Әгәр җөнүб булсагыз, юынып пакьләнегез!»

Әйткәнебезчә, Ислам дине безне тәнебезне, киемнәребезне, яшәгән җирләребезне чисталыкта тотарга өнди. Коръән аятьләрендә генә түгел, ә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күп кенә хәдисләрендә дә бу турыда әйтелә:

«Ризыкның бәрәкәте (хәере) – ашар алдыннан һәм ашаганнан соң кулларны юудан гыйбарәт» (Тирмизи).

«Башны һәм тәнне атнага бер мәртәбә юу – һәрбер мөселманның Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычы» (Бохари, Мөслим).

Икенче бер хәдистә суның ике дөньяда да иң яхшы эчемлек булуы хакында искә алына: «Су фани һәм бакый дөньядагы барлык эчемлекләрнең хуҗасы». Шуңа да, су эчкәндә билгеле бер кагыйдәләрне (әдәпләрне) үтәү тиешле.

# Су эчкәндә биш кагыйдәне исеңдә тот!

1. Суны акрын гына, ашыкмыйча эчәргә кирәк.

Гали радыяллаһу ганһедән тапшырылган бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткәне риваять ителә: «Суны авыз тутырып түгел, акрынлап эчегез».

2. Суны берьюлы түгел, ә ике, өч йотымда эчәргә киңәш ителә, ләкин шул ук вакытта су салынган савыт эченә, ягъни су өстенә суларга ярамый.

Әбү Сәид радыяллаһу ганһе тапшыра: Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Су салынган стаканыңны авызыңнан читкәрәк җибәр һәм аннан соң сула», – дип әйткән.

Әбү Катадә тапшырган хәдистә китерелә: Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Сезнең берәрегез су эчсә, суга өрмәсен», – дип әйткән.

3. Мөмкинлек булганча суны утырган хәлдә эчү хәерле, әгәр инде мондый мөмкинлек булмаса, баскан хәлдә дә ярый.

Бер риваятьтә Гали радыяллаһу ганһенең Куфада, мәчет ишегеянында баскан хәлендә су эчкәне әйтелә. Шул чагында ул: «Кемнәрдер басып су эчүне килешле гамәл дип санамый. Ләкин мин үзем Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең баскан хәлендә су эчкәнен күрдем», – дип әйткән.

4. Су салынган савытны уң кул белән алу хәерле. Гомәр радыяллаһу ганһе сөйләвенчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәрегез ашаса яки эчсә, уң кулы белән ашасын һәм эчсен, чөнки сул кул белән шәйтан ашапэчә», – дип әйткән (Мөслим).

5. Эчәр алдыннан: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим», ә эчеп бетергәч: «Әлхәмдүлилләһ», дип әйтергә кирәк.

Әбү Һөрайрадан риваять ителгән озын бер хәдиснең азагында болай дип әйтелгән: «Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам сөт салынган савытны кулына алып, «Бисмилләһ», дип әйтте һәм эчте, ә аннан соң Аллаһыны мактады» (Тирмизи).

# Җирдәге иң яхшы су

Су турында сүз кузгаткач, әлбәттә инде, Зәм-зәм чишмәсен телгә алмый мөмкин түгел. Тарихчылар раслаганча, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Зәм-зәм суын «җирдәге иң яхшы су», дип атаган. «Анда Ризыкландыручының азыгы һәм төрле чирләрдән дәва бар», – дип әйткән.

Зәм-зәм чишмәсенең тарихы Ибраһим галәйһиссәлам белән хатыны Һаҗәр радыяллаһу ганһә хакындагы риваятькә барып тоташа. Риваятькә караганда, Ибраһим галәйһиссәлам, Аллаһының әмерен үтәп, Һаҗәрне күкрәк баласы Исмәгыйль белән, аларга су һәм хөрмә биреп, булачак Зәм-зәм чишмәсе урынында калдырып китә. Үзләре белән булган ризыклары беткәч, Һаҗәр Сафа һәм Мәрва таулары арасын 7 тапкыр йөгереп үтә. Ләкин бернәрсә дә таба алмый, Аллаһыга дога белән ялвара. Аллаһы Тәгалә догасын кабул кыла. Нәни улының аяк үкчәсе янынннан чишмә бәреп чыга һәм ул Зәм-зәм дип атала.

Сусаудан һәм ачлыктан җәфаланып, Һаҗәр ананың чүлдә су эзләп йөгереп йөрүенә һәм Аллаһы Тәгаләнең аларны саклап калу өчен Зәм-зәм суы бүләк итүенә дә дүрт мең ел узган. Әлеге чишмә һәм аның суы бүгенге көнгә кадәр галимнәрнәрдә күп сораулар тууга сәбәпче булып тора. Шактый еллар үтүгә карамастан, чишмәнең суы кимеми. Чүлдә булса да, бернинди корылык та аңа киртә түгел. Суның химик составы бер дә үзгәрми. Әлеге чишмә суы бик күп еллар тәмле һәм саф килеш саклана. Күп елларга сузылган тикшерүләр әлеге суның бай составы турында сөйли. Зәм-зәм суында, башка сулардан аермалы буларак, күп күләмдә кальций һәм магний тозлары бар. Шулай ук ул тимер, бакыр, бикарбонатларга да бик бай.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, су эчкәндә үтәлергә тиешле әдәпләр – болар барысы да сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күркәм үрнәге – сөннәте. Шул сәбәпле, су эчкәндә дә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтенә таянсак, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә Кәүсәр чишмәсеннән сулар эчерер, ин шә Аллаһ.

*Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде*

# Кәгъбәдәге Кара таш

Ел дәвамында Мәккә шәһәренә хаҗ һәм гомрә гыйбадәтләрен үтәргә җирнең төрле почмакларыннан миллионлаган мөселманнар агыла. Һәр хаҗи изге Кара ташны үбәргә яки аны тотып карарга хыяллана. Кара таш (гарәпчә «хәҗәр әл-әсвәд») Кәгъбәнең көнчыгыш почмагында, 1,5 м биеклектә куелган. Ташны Кәгъбә диварына Ибраһим пәйгамбәр урнаштыра. Кара таш янында һәрвакыт махсус сакчылар тора. Алар Ташны саклый да, хаҗиларга аңа тотынырга ярдәм дә итә. Сакчылар һәр сәгать саен алышына, шул рәвешле, бу эштә 24 кеше эшли. Әлеге вазифага фәкать яхшылап тикшерелгән, сәламәт, чыдам һәм яхшы физик формада булган ир-атлар гына алына.

Һәр намаздан соң Кәгъбә чистартыла һәм дезинфекцияләнә. Моның өчен гөлчәчәк (роза) суы, махсус чистарткычлар, зәм-зәм суы кулланыла.



# Кисвә турында 10 факт

1. Кисвә – Изге Кәгъбәне каплый торган махсус япма.
2. Кисвәне ел саен зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көнендә алыштыралар, хаҗилар бу вакытта Гарәфәт тавында була.
3. Кайбер галимнәр фикеренчә, Кәгъбәне кисвә белән каплау гадәте Исмәгыйль пәйгамбәр заманыннан ук килә.
4. Кисвәне әзерләү өчен махсус остаханә эшләп килә.
5. Бу остаханә 1927 елда оештырыла.
6. Кисвәне өч ай дәвамында якынча 240 оста әзерли.
7. Кисвә биш өлештән тора. Аның берсе Кәгъбәнең ишеген каплый.
8. Кисвәне озынлыгы 14 м, киңлеге 101 см булган 47 өлештән тегәләр.
9. Кисвә тукымасын әзерләүгә 450 кг якын ефәк китә.
10. Ел да ике кисвә әзерләнә: берсе белән Кәгъбәне каплыйлар, икенчесе кирәге чыкса дип, сакланып тора.

# Кисвәдәге чигү хакында

Бүгенге көндә Кисвәнең рәсми хаттаты (каллиграфы) булып Мохтар Галим Шәкдар тора. Аңа кадәр бу мәртәбәле вазифаны Габдрахим Бохари башкарган, ул 1996 елда 90 яшендә вафат булган.

1978 елда Галим Шәкдар Әл-Харам мәчете каршында эшләп килгән хаттатлар мәктәбенә укырга керә. Монда ул ике ел укый. Бу вакытта ул әле дүртенче сыйныфны тәмамлаучы укучы булган.

Бакалавриат тәмамлап, югары белем алганнан соң, Галим Шакдар егерме ел дәвамында төрле уку йортларында хатт гыйлемен (каллиграфия) укыта. Бүгенге көндә ул – хатт гыйлеме магистры дәрәҗәсенә ия һәм Әл-Харам мәчетендә мөгаллимлек итә.

Оста сүзләренчә, Кисвәне әзерләү остаханәсенә эшләргә аны 2003 елда чакыралар. Эшләрендә алар заманча компьютер технологияләрен кулланалар. Кисвәдәге бар язулар, хатт үрнәкләре Габдрахим Бохари эшләп калдырган үрнәкләр буенча бастырыла. Мохтар Галим Шакдар үзенең фәкать берничә бизәк һәм корольләр Салман һәм Габдулланың исемнәрен өстәвен әйтә.

Куплэрне Кисвәдә Коръән сүрәләре ничек язылуы кызыксындыра. Остаханәдә әзер шаблоннар кулланыла, алар белән эш берничә этаптан тора. Әүвәл текстны кулдан кәгазьдә язалар, аннан соң аларны компьютерда эшләүче рәссам эшкәртә. Камилләштерелгән текст үтә күренмәле махсус кәгазьдә бастырыла. Әлеге шаблоннар тегүчеләргә бирелә, алар инде изге язмаларны алтын һәм көмеш җепләр белән чигәләр. Заманча технологияләр куллану Кисвәне әзерләүне күпкә җиңеләйтә, шул ук вакытта япма үзенең кабатланмас матурлыгын һәм үзенчәлеген саклап кала.

# Россиядә хаҗ тарихы

Бүгенге Россия территориясенә караган җирләргә Ислам дине бик иртә үтеп керә. Мәсәлән, Дәрбәнт (Дагъстанда) инде һиҗри буенча 22 нче елда ук хәлифәлек составына керә. Белгәнебезчә, Идел Болгарында Ислам рәсми рәвештә 922 елда кабул ителә.

Димәк, безнең җирләрдә дә зур гыйбадәтне үтәүчеләр – хаҗ кылучылар булган. Ара ераклыгын искә алганда, әлбәттә, ул чорларда бездә хаҗилар күп булмаганлыгы аңлашыла. Әмма галимнәр, сәүдәгәрләр, вәзирләр кебек сәясәткә бәйле булган кешеләрнең хаҗ кылу мөмкинлеге булган. Ул вакытта хаҗ сәфәре гыйбадәт кенә түгел, ә Россия мөселманнары өммәтен Ислам дөньясы белән бәйли торган җеп тә булган.

Илебездә хаҗ тарихына бәйле кайбер мисалларны карап китик. 1494 елда Казан ханбикәсе Нурсолтан Каһирә аркылы барып, хаҗ кылып кайта. 1512 елда ул хаҗ гыйбадәтен икенче тапкыр үти. 1524 елда Сахибгәрәй хан хаҗ кылып кайтыр өчен, Казан ханлыгында идарә эшләрен Сафагәрәй ханга калдырып тора.

Язма истәлекләрдән безгә кайбер татар руханиларының, шулай ук Кавказ, Башкортстаннан имамнарның хаҗ кылуы мәгълүм.

Хаҗ турында искә алынган беренче юридик документ Россиядә бары 1803 елда гына барлыкка килә. Анда Россиядәге бохаралыларга хаҗга барырга рөхсәт ителүе хакында әйтелә.


1855 елда Россия гражданнарына чит ил паспортлары бирелә башлый. Моңарчы хаҗиларның чит илләргә нинди документлар белән чыгуы билгеле түгел. Язма истәлекләргә караганда, хаҗ сәфәренә чыгарга рөхсәт итә торган документны алуны кыенлаштыру өчен аерым эш алып барылган. Мисал өчен, 1877 елда Казанда «Хаҗның дини һәм сәяси әһәмияте» дип аталган китап чыга. Анда кайвакыт мөселманнарга хаҗга барырга тыелуы хакында искә алына. Автор мондый кануннарны бик хуплап, мөселманнарга гомумән Мәккәгә хаҗ кылуны тыярга кирәк, бу мөселманнарга да, башка дин әһелләренә дә бик файдалы булачак, дигән фикерен китерә. Әмма, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, мондый канун кабул ителми.

XIX гасырда Россия мөселманнарының хаҗ сәфәре нигездә өч юл буенча ашырылган:

1. Кавказ һәм Фарсы дәүләтенең төньяк өлешеннән Багдадка таба, ә аннан соң, истәлекле урыннарны зиярәт итеп, ком чүлләре аша – Мәккә вә Мәдинәгә. Бу юл буенча ел да 12-15 мең кеше хаҗга барган.
2. Сәмәрканд һәм Бохара аша Әфганстанга, аннан Бомбейга, аннан су юлы белән Җиддәгә һәм Мәккә белән Мәдинәгә. Бу юл нигездә Урта Азия мөселманнары өчен уңайлы булган, аның буенча 4-7 мең тирәсе мөселман хаҗ кылган.
3. Истанбул аша Җиддәгә һәм Мәккә белән Мәдинәгә. Бу юл исә чагыштырмача кыска һәм җиңелрәк булган. Аның буенча безнең бабаларыбыз, татарлар, шулай ук кайбер кавказлылар һәм башка милләт вәкилләре дә хаҗ кылган. Аларның саны бик зур булмаган – елына якынча 2-3 мең хаҗи.

■ **Сәхифә Islam-today.ru материаллары нигезендә әзерләнде**

# Коръән укуның файдасы



Тауларда үзенең оныгы белән бер карт кына бабай яшәгән, ди. Ул мөселман булган, шуңа да һәр иртәсен Коръән укуга багышлаган. Оныгы аңа охшарга тырышкан, бабасы ни эшләсә, шуны кабатлап барган.

Бервакыт бу бала: «Бабай, мин Коръән китабын синең кебек укып барырга тырышам, әмма мин аның мәгънәсен аңламыйм. Мин китапны ябу белән, ятлаган әйберләрем башымнан чыга. Шулай булгач, Коръәни Кәрим китабын укудан нинди файда бар соң?» – дип сорый.

Мичкә ташкүмер сала башлаган бабасы, туктап: «Бар, улым, ташкүмер кәрҗинен ал да, елгага төшеп, су алып мен», – дип әйтә.

Онычы шулай эшли дә, кәрҗинне алып, су алып менәргә төшеп китә. Әмма ул тау башына менеп җиткәнче, су кәрҗиннән агып беткән иде инде.

Моны күреп, бабасы елмаеп куя һәм: «Син тизрәк атлап кара», – дип әйтеп, онычын кабаттан су алырга төшереп җибәрә. Монысында инде малай тизрәк атларга тырыша. Әмма тау башына йөгереп менеп җиткәнче, кәрҗин буш була. Бабасына суны кәрҗиндә алып менеп булмаганлыгын хәбәр итеп, малай чиләк артыннан китә. Бабасы моны күреп: «Әмма миңа бер кәрҗин су кирәк, миңа бер чиләк су кирәкми. Син бар көчеңне куеп эшләргә теләмисең генә», – дип каршы төшә.

Онычы бу хәлнең мөмкин түгеллеген исбатлар өчен, кабаттан елга буена төшеп китә. Ул кәрҗине белән су тутырып ала да, бар көченнән бабасы янына чаба башлый. Әмма менеп җиткәнче, су агып беткән була.

Хәленнән тайган малай: «Менә, бабай, әйттем бит мин сиңа – болай булмый», – дип нәтиҗә ясап куя. «Син моны мәгънәсез дип уйлыйсыңмы?» – дип сорый бабасы, – «Кәрҗингә кара әле». Онычы кәрҗингә караса, ташкүмердән каралып беткән кәрҗиннең эчтән дә, тышкы яктан да чистарганын күреп ала.

«Балам, Коръән укыган вакытта менә ниләр була. Син аны укыган вакытта аңламаска да, истә дә калдырмаска мөмкинсең. Әмма ул сине эчке яктан да, тышкы яктан да үзгәртергә сәләтле. Менә шул рәвешле Аллаһы Тәгалә безнең тормышыбызны да үзгәртә».

# Югалган хәзинә

Бер караңгы төнне Имам Әбү Хәнифә янына бер кеше килә һәм: «Кайчандыр мин акчаларымны яшереп куйдым, әмма кая яшергәнемне хәтерләмим. Шуңа сез табарга ярдәм итә алырсыз дип, киңәш сорап килдем», – дип әйтә.

Әбү Хәнифә уйлап тора да: «Әлбәттә, югалганны эзләү минем эшем түгел. Шулай да, сезгә ярдәм итеп карыйм. Киңәшем шул: өегезгә кайтыгыз да, таң атканчы намазлар укыгыз. Минемчә, байлыкны кая яшергәнегез исегезгә төшәр», – ди.



Ир-ат өенә кайтып китә дә, имам киңәше буенча намазга баса. Намазга баскач ук, ул акчасын кая яшергәнен исенә төшерә. Тиз генә намазын укып бетереп, акчаларын табып алып кайта.

Икенче көнне иртән бу кеше янә Әбү Хәнифә янына килә һәм шатлыклы яңалыгын хәбәр итә. Аннан: «Намаз укый башлагач та исемә төшәсен ничек белдегез?» – дип сорый.

Әбү Хәнифә исә: «Намазда сезне Иблис тынычлыкта калдырмаячагын, таң атканчыга кадәр намаз укымасагыз иде дип, акчаларыгызны кая яшергәнне исегезгә төшерәчәген белә идем», – дип җавап кайтара.

Шулай еш кына адәм баласы чын байлыкны вакытлы малга алыштыра.

# Шәфкатьле хаким

Чүлдә бер кечкенә генә кавем яшәгән. Бу кавемгә юлбасарлардан берниди дә тынычлык булмаган: алар һәрвакыт шул юлбасарлар килерләр дә, бар булган малмөлкәтне талап китәрләр, дип курка яшәгәннәр. Юлбасарлар да гомумхалык кагыйдәләренә буйсынмыйча, нәрсә ала алганнар, кемне талый алганнар – шуны талаганнар.

Бу кавем чүлдә үзләре генә яшәгәнгә карамастан, аларда мал да, ризык та җитәрлек булган. Әмма шушы юлбасарлар аркасында хәлләре мөшкелләнә башлаган. Шуннан соң алар бу җирлектәге дәүләт башлыгыннан ярдәм сорарга булганнар. Хаким үзе гаскәр туплап, бу җирләргә килергә уйлаган. Моның турында хәбәрләр халыкка бик тиз килеп ирешкән, шуңа да юлбасарлар тауларга качып беткәннәр. Хаким гаскәр белән килеп җитүгә, аларга юлбасарларның тауларга качканнарын хәбәр иттеләр.

Бераздан җил чыгып, яшенле яңгыр башланды. Дәүләт башлыгы да юешләнде, шуңа яңгырдан соң ул киемен киптерер өчен урын эзли башлады. Бер агач янына туктап, ул өске киемен салып, ботакка элеп куйды. Арганлыктан, ул шул ук агач төбенә ял итәргә дип ятты. Моны ерактан бер юлбасар күзәтеп торды. Ул: «Бу хакимнән котылу өчен менә дигән форсат бит», – дип уйлап, шул агачка таба юнәлде. Тавышсыз гына таудан төшеп, йоклап яткан хаким янына килде. Кыриендагы кылычны күреп, аны хакимнең йөзенә таба китерде дә: «Сине минем кулдан кем коткарыр?» – дип көлеп җибәрде. Хаким уянып, аңа кылыч белән янаган кешене күрде. Ул тыныч кына: «Мине Аллаһы коткарыр», – дип җавап бирде.

Юлбасарның кулы калтырый башлап, кылычы җиргә төшеп китте. Хаким кылычны күтәреп алып: «Ә сине минем кулымнан кем коткарыр?» – дип сорады. Хаким үз гомерен саклау ниятеннән бу кешегә зыян да сала ала иде, әмма ул аннан үзенеке кебек җавап көтте. Тик бу кеше тәкъдимне кире какты. Шулвакыт дәүләт башлыгы: «Алайса, бар. Син юлны беләсең», – дип, бу кешене иреккә җибәрде. Юлбасар тиз генә китә башлады, әмма бераз баргач, борылып: «Мин беркайчан да сиңа каршы сугышмам һәм сиңа каршы сугышканнарга да кушылмам», – дип әйтеп, китеп барды.

Инде бу хакимнең дә кем икәнен әйтсәк буладыр: ул – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм иде.




## «Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре»

Хаҗ сәфәре – фарыз гамәл һәм һәр мөселман ның тормышында олы вакыйга. Йөз ел элек татар кешесе хаҗга нинди юл белән барган? Изге урыннарны күрер өчен күпме вакыт таләп ителгән? Бу хакта бөек татар галиме, дин әһеле, фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтнең хаҗнамәсендә бәян ителә. Мәгърифәтче 1880 елда хаҗ сәфәренә чыгып, галимнәр белән очрашулардан, төрле шәһәрләрдән тәэсирләрен хәтер дәфтәрендә теркәп барган. Шушы хатирәләрне аерып алып, аңлатмалар биреп, Ризаэтдин Фәхретдин басмага әзерли.

«Хозур» нәшрият йорты әлеге хезмәтне хәзерге татар әдәби теленә күчереп, 1898 елда гарәп имләсендә чыккан нөсхәне дә кертеп, «Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре» китабын нәшер итте.

**Китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 14 нче йорт (РИИ бинасы) һәм Тукай урамы, 36 нчы йорт адреслары буенча урнашкан кибетләрдән алырга мөмкин.**
**Телефон: +7 (903) 305-45-43**




## КАЗАН ӨЧЕН МАРТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.03.2019 | 04:32 | 05:05 | 06:35 | 12:00 | 15:19 | 17:17 | 18:58 |
| 02.03.2019 | 04:30 | 05:03 | 06:33 | 12:00 | 15:21 | 17:19 | 19:00 |
| 03.03.2019 | 04:27 | 05:00 | 06:30 | 12:00 | 15:23 | 17:21 | 19:02 |
| 04.03.2019 | 04:25 | 04:58 | 06:28 | 12:00 | 15:25 | 17:23 | 19:04 |
| 05.03.2019 | 04:22 | 04:55 | 06:25 | 12:00 | 15:27 | 17:25 | 19:06 |
| 06.03.2019 | 04:20 | 04:53 | 06:23 | 12:00 | 15:28 | 17:27 | 19:08 |
| 07.03.2019 | 04:17 | 04:50 | 06:20 | 12:00 | 15:30 | 17:29 | 19:11 |
| 08.03.2019 | 04:14 | 04:48 | 06:18 | 12:00 | 15:32 | 17:31 | 19:13 |
| 09.03.2019 | 04:12 | 04:45 | 06:15 | 12:00 | 15:34 | 17:33 | 19:15 |
| 10.03.2019 | 04:09 | 04:42 | 06:12 | 12:00 | 15:36 | 17:35 | 19:17 |
| 11.03.2019 | 04:06 | 04:40 | 06:10 | 12:00 | 15:37 | 17:38 | 19:19 |
| 12.03.2019 | 04:03 | 04:37 | 06:07 | 12:00 | 15:39 | 17:40 | 19:21 |
| 13.03.2019 | 04:00 | 04:35 | 06:05 | 12:00 | 15:41 | 17:42 | 19:24 |
| 14.03.2019 | 03:58 | 04:32 | 06:02 | 12:00 | 15:42 | 17:44 | 19:26 |
| 15.03.2019 | 03:55 | 04:29 | 05:59 | 12:00 | 15:44 | 17:46 | 19:28 |
| 16.03.2019 | 03:52 | 04:27 | 05:57 | 12:00 | 15:46 | 17:48 | 19:30 |
| 17.03.2019 | 03:49 | 04:24 | 05:54 | 12:00 | 15:47 | 17:50 | 19:33 |
| 18.03.2019 | 03:46 | 04:22 | 05:52 | 12:00 | 15:49 | 17:52 | 19:35 |
| 19.03.2019 | 03:43 | 04:19 | 05:49 | 12:00 | 15:51 | 17:54 | 19:37 |
| 20.03.2019 | 03:40 | 04:16 | 05:46 | 12:00 | 15:52 | 17:56 | 19:40 |
| 21.03.2019 | 03:37 | 04:14 | 05:44 | 12:00 | 15:54 | 17:58 | 19:42 |
| 22.03.2019 | 03:34 | 04:11 | 05:41 | 12:00 | 15:56 | 18:00 | 19:44 |
| 23.03.2019 | 03:31 | 04:09 | 05:39 | 12:00 | 15:57 | 18:02 | 19:47 |
| 24.03.2019 | 03:27 | 04:06 | 05:36 | 12:00 | 15:59 | 18:04 | 19:49 |
| 25.03.2019 | 03:24 | 04:03 | 05:33 | 12:00 | 16:00 | 18:06 | 19:51 |
| 26.03.2019 | 03:21 | 04:01 | 05:31 | 12:00 | 16:02 | 18:08 | 19:54 |
| 27.03.2019 | 03:18 | 03:58 | 05:28 | 12:00 | 16:03 | 18:10 | 19:56 |
| 28.03.2019 | 03:15 | 03:56 | 05:26 | 12:00 | 16:05 | 18:12 | 19:59 |
| 29.03.2019 | 03:11 | 03:53 | 05:23 | 12:00 | 16:07 | 18:14 | 20:01 |
| 30.03.2019 | 03:08 | 03:50 | 05:20 | 12:00 | 16:08 | 18:16 | 20:04 |
| 31.03.2019 | 03:04 | 03:48 | 05:18 | 12:00 | 16:10 | 18:18 | 20:06 |

## «Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2019 елның икенче яртысына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Февраль саны, №2 (283)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2746
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 19 нчы февральда таратыла.
График буенча бу санга 18 нче февраль көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.